
بسم الله الرحمن الرحيم

Эзләнү-тикшеренү сериясе

Басма №: 64

Әхмәт Ясәви

Редактор

Проф, фәннәр докторы Нәждәт Тосун

Тел адаптациясе

Муса Озынкайа

Тәрҗемә

Филология фәннәре кандидаты Эльмира Хабибуллина

Басма координаторы

Харун Сарыгуль

Миниатюра

Җиһангир Ашуров

ISBN: 978-9944-237-77-2

Басылу датасы: 2020

© Әхмәт Ясәви Университеты

Рәисләр Шурасы Җитәкчесе

Ташкент Проспекты, Шәһит Һ.Темел Кууоглу урамы, № 30 06490
Бакчалыәвләр/ Анкара

Тел: 0312 216 06 00 • Факс: 0312 223 34 29

www.ayu.edu.tr yayinlar@yesevi.edu.tr

Китапта урын алган фикер һәм күзаллаулар бары тик авторлар тарафыннан белдерелеп, Әхмәт Ясәви Университеты Рәисләр Шурасы Җитәкчелегенең күзаллауларына туры килмәскә мөмкин.

Ankara - 2020

ХУҖА ӘХМӘТ ЯСӘВИ





Эчтәлек

7 Сүз башы / Профессор, фәннәр докторы Муса Йылдыз

11 Кереш/ Профессор, фәннәр докторы Нәждәт Тосун

15 Хуҗа Әхмәт Ясәви

19 Тормышы

23 Әсәрләре

25 Риваятьләре

31 Төрбәсе

35 Ясәвилек

41 Ясәвилектә суфыйчыл тәрбия

48 Библиография

51 Хикмәтләр

114 Сылтамалар



جهانگیر بخاری

СҮЗ БАШЫ

фәннәр докторы Муса Йылдыз

Шәех-и Хәзрәт-и Төркистан Әхмәд Ясәви – югары әхлак, гашыйк һәм ирфан адәме, Аллаһының дусты. Гомумтөрки мәдәният тарихыбызның иң әһәмиятле шәхесләреннән берсе булган. Ул Арыслан Бабы Йосыф Хәмәдани Хәзрәтләренең күңелендә уяткан Ислам диненә карата мәхәббәт һәм ирфан үсентеләрен бары тик үзеннән соңгы укучыларына ирештерү белән генә чикләнмәгән. Бәлки дә үзе тәрбияләгән суфый Алыпәрәнләрен Азиянең бер очыннан Аврупа чикләренә кадәр җибәреп кешеләргә гаделлек, күндәмлек, берлек һәм иминлек *кебек төшенчәләрне ирештерүне максат итеп куйган.*

Ясәви Хәзрәтләре шул чорның дин һәм мәдәният телләре вазыйфасын үтәгән гарәпчә һәм фарсыча урынына ана теле төркичәне кулланган, төрки телне гыйлем, мәхәббәт һәм ирфан теле дәрәҗәсенә күтәргән. Чыгышларында һәм нотык рәвешендә язган хикмәтләрендә ана теле төркичәне кулланып киң катлам кешеләргә йогынты ясаган һәм Төрки суфый язучысы булган.

Бүген киң географиядә язу һәм сөйләм теле буларак кулланылган төрки тел турында сүз бара икән, моның төп сәбәпчесе Олуг Шәех Әхмәд Ясәви.

Икенче яктан, Әхмәт Ясәви Хәзрәтләре үз вакытында Ислам дине чикләрен бозып читкә тайпылучы, Аллахы тәгаләдән башка барлыкларга

табынучы һәм имансыз буларак билгеләнүче сөннәтне бозучы агымнарга каршы Коръән һәм Сөннәт байрагын күтәргән шәхес. Ул – Коръәнне шәрехләп Пәгаймбәр Хәзрәтләре ирештергән һәм өйрәткән чын Ислам динен халыкка тапшырган шәхес. Коръәндә Аллахы Тәгаләгә булган мәхәббәтнең бөеклеген аңлаткан шәхес.

Шул рәвешле Әхмәт Ясәвине искә алу белән, Пәйгамбәр Хәзрәтләре безгә өйрәткән Ислам динен ана телендә, һәркем аңлый алырлык төрки телдә шәрехләгән беренче төрки мутассавыф һәм ул тәрбияләгән суфый Алыпәрәнләр белән бергә Ислам диненең тәүхит һәм гаделлек нурын җиһанга тарату өчен җан аткан бер төркем юл салучылар күз алдына килеп баса.

Төркистанның Хәзрәте бары тик үз милләте өчен генә түгел, сөйләгән вәгазьләре белән бөтен дөнья өчен әһәмияткә ия. Чыннан да аның шәхесе белән бәйле Ясәвилек юлының төп асылы Ислам динен төркичә шәрехләүгә кайтып кала. Аллахы тәгалә, Пәйгамбәр һәм Җан иясенә карата мәхәббәтен күңелендә туплаган бу бөек шәхес мәхәббәт һәм ирфанның, самимилыкның, нечкә күңеллекнең, кешегә карата ихтирам һәм сөүнең тирәнәю һәм киңәюенең символы булып тора.

Бер шигырьдә Төркистанның йөрәге шул рәвешле тасвирлана:

Төркистанның калебе Әхмәт Ясәви
Гашыйк иткән барча күңелләрне
Туплаган тирәсендә Алыпәрәнләрен
Әйткән егетләргә: Ирлек юлы бу
Әрәнләр хакыйки ярлык юлы бу

Начарлык серен Арслан Бабадан
Алып факыйрь тунын кигән карадан
Биргән рөхсәтен Йосыф Хәмәдан
Әйткән соң чиктә муллык юлы бу
Нәфсен тыя белгәннең хөрлек юлы бу

Бу яшел гөмбәздә сүз әйткән Шәех

Хикмәте сүзләр белән аңлатып бер-бер

Вахиның телендә Төркичә эндәшә

Әйтә ул: Төркистанга бердәмлек юлы бу,

Аман таралмагыз яшәүнең юлы бу...

Тәкъбир тавышларыннан далага су тула

Җилгә кушылып "Ул" сүзе ишетелә

Ясәви төрбәсендә нурга күмелә

Әйтә ул Төрки кардәш! Бердәмлек юлы бу

Аерылма Коръәннән, яшәүнең юлы бу.

(*Мостафа Татчы*)

Ясәви корган дөньяны без, ул ягып җибәргән чыра чаткылары ярдәмендә бүгенге көндә яшәтергә омтылабыз. Шул рәвешле кулыгыздагы бу әсәр миссиябезнең бер өлеше.

Бу әсәрне әзерләүдә көч түккән профессор, доктор Нәҗдәт Тосунга, хикмәтләрен төрек теленә шигъри тәрҗемә иткән Муса Узункайага, текстларны гадиләштерүдә ярдәм иткән профессор, доктор Зөлфикар Гюнгерга һәм хезмәтләрен керткән һәрбер кешегә рәхмәтләребезне ирештерәбез.

Профессор, фәннәр докторы

Муса Йылдыз

Әхмәт Ясәви Университеты

Рәисләр Шурасы Җитәкчесе



КЕРЕШ

фәннәр докторы Нәждәт Тосун

XII. гасырда *Урта Азиядә яшәгән Хуҗа Әхмәт Ясәви һәм Ислам дине таралуына һәм дә әхлак һәм рух төшенчәләренең ныгуына зур өлеш керткән. Аерым алганда ул сөйләгән хикмәт-шигырьләрендә төрки тел һәм әдәбиятына әһәмиятле хезмәте кергән зур галим, суфый һәм шагыйрь. Аның турында телдән-телгә тапшырылган риваятьләр һәм үзе иҗат иткән дип саналган берничә рисаләне искә алмаганда аның кичерешләрен һәм күзаллауларын бүгенге көнгә кадәр ирештерүче әсәрләр арасында шигырьләре җыелган Хикмәтләр Җыентыгы һәм дә укучысы һәм мөриде Суфый Мөхәмәд Данышмәнди язган Мирагатуль-Кулуб исемле әсәре сакланган.*

Хикмәтләр Җыентыгының язылган нөсхаларында шигырь саннарының төрлечә булуы һәм искерәк язмаларының аз санда булуы әсәрнең телдән телгә тапшырылып, соңыннан кәгазьгә күчерелгәч кенә төрлечә җыйналуын дәлилли. Хәтта кайбер җыентыкларында башка шагыйрьләрнең шигырьләре дә урын алган дигән фараз бар. Шуның белән бергә Хикмәтләр Җыентыгында бөтен шигырьләр Хуҗа Әхмәт Ясәвинең дин, әхлак һәм суфыйчыл күзаллауларын яктыртып тора.

Ясәвинең күңел дөньясын бугенге көнгә кадәр яктыртып торучы

бу шигырьләр Көнчыгыш төрки теле язу традицияләре кысаларында Чыгатай телендә язылганга күрә бүген дә бик җиңел аңлашыла. Бу шигырьләр һәм бүгенге көн төрки телләренә һәм дә инглиз һәм рус теле кебек дөньяда таралган телләргә тәрҗемә ителеп күп санлы кешеләргә ирештерелүгә мохтаж.

Югарыда искә алынган эшне гамәлгә ирештерү максаты белән Хикмәтләр җыентыгыннан иң мөһим дип саналган хикмәтләр сайланды, төрек теленә тәрҗемә ителде һәм массакүләм кешеләр укып аңлый алырдай сайланма шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Шуның белән бергә Хикмәтләр җыентыгы йөзъеллар дәвамында гарәп графикасында язылу сәбәпле, аның беренчел язылу ысулын да күрсәтә алу, шул истәлекне саклап калу һәм киләчәк буынга бу сәнгатьне ирештерә алу максатыннан чыгып без сайланган хикмәтләрне гарәп язуы белән, латин хәрефле транскрипциясе һәм гадиләштерелгән варианты белән янәшә урнаштырып бастырдык. Хуҗа Әхмәд Ясәвинең тормышын һәм мажараларын яктырткан миниатюралар һәм каллиграфия ысулы белән язылган кайбер шигырь үрнәкләре кыйммәтле сәнгать әсәрләре рәтендә тора. Һәм нияять барлыкка килгән бу матур сәнгать әсәре Хуҗа Әхмәд Ясәвинең тормышы, мажаралары һәм Ясәвийә тәрәккатенең асылын яктырткан кереш өлеше белән янәшә укучыларыбызның игътибарына тәкъдим ителде.

Хикмәтләр җыентыгыннан өлешләр гарәп графикасында язылган иске басулы нөсхәләрдән сайланып алынды. Аларның беренчесе 1904 елгы Казан басмасының Дайрабай Серикбайулы һәм С.Рафиддинов тарафыннан 2001 елда Алма-Атада янә дә гарәп хәрефләре белән компьютерда бастырылган нөсха. Икенчесе исә Куанышбәк Кари, Галия Камбарбекова һәм Расуль Исмаилзадә тарафыннан һәм гарәп графикасында һәм дә казах теленә транскрипциясе бирелеп 2000 елда Тәһранда чыккан басмасы. Икенче китапны әзерләүчеләр Хикмәтләр җыентыгының 1893 елгы Казан һәм 1897 елгы Истанбул басмаларын нигез итеп алулары сәбәпле без дә эшебездә күбрәк шул китаптан файдаландык.

Сайланып алынган хикмәтләрнең бүгенге төрек теленә тәрҗемәсен / адаптациясен Муса Озынкайа башкарды, аның белән янәшә профессор, фәннәр докторы Кемал Эрарслан һәм фәннәр докторы Хайати Биҗә башкарып чыккан басмалардан да файдаландык. Каллиграфия һәм миниатюралары белән янәшә гыйлем һәм сәнгать әсәре булган бу китапны хәзерләп башкарып чыккан коллектив исеменнән китапны нәшер иткән Әхмәт Ясәви университетына рәхмәтбезне җиткерәбез.

Профессор, фәннәр докторы Нәҗдәт Тосун



ХУҖА ӘХМӘТ ЯСӘВИ

Урта Азиядә Ислам дине таралу белән бер вакытта Хиҗри календаре белән II гасырдан (Милади белән VIII гасыр) башлап ул җирләрдә мистик һәм суфыйлар дә очрый. Бүгенге Төрекмәнистан чикләре эчендә урнашкан Мәрвә шәһәрендә туган Абдулла бине Мөбәрәк (үлгән елы 181/797) хәдис белгече һәм шул ук вакытта мистик һәм суфый кеше иде. Мәрвә шәһәрендә ике тәккә коруы һәм шул җирләрдә халыкка дини фикерләрне таратуы турында язылган. Үзбәкстан чикләре эчендә урнашкан Нахшәб (бүгенге исеме Каршы) һәм Тырмыз шәһәрләре шулай ук шактый гына галим һәм суфый туып үскән өлкәләрдән. “Суфыйны берни дә болгата алмый, киресенчә бар нәрсә алар ярдәмендә саф һәм чиста хәлгә килә”, - диюче Әбү-Түраб Нәхшеби (үлгән елы 245/859-860) һәм суфыйчыл фикерләре ярдәмендә танылган һәм күп санда гарәп суфыйчыл әсәрләр язучы Хаким Тырмызи (м. 320/932-933) шул суфыйларның иң мәшһүрләре. Хаким Тырмызинең кабере Тырмыз шәһәрендә бүгенге көндә дә әһәмиятле зыярәт урыны.

Бохара һәм Сәмәрканд шәһәрләре исә һәм галимнәр һәм дә

суфыйлары белән Урта Азиянең иң әһәмиятле мәдәният үзәге булып торган. Бохараның Келабаз (Келабад) мәхәлләсендә яшәгән Әбү-Бәкир Мөхәммәд бине Исхак Келабази (ү.е. 380/990) суфыйчыл догмаларын “Әт-Тааруф ли Мәхһәби Әһлит-Тасаввуф” исемле гарәпчә язылган әсәрендә туплаган. Аерым алганда Бахрул-Фәваид исемле әсәрендә кайбер хәдисләргә суфыйчыл шәрехләр ясаган.


Үзе җыеп үткәргән дини мәҗлесләрдә укыган суфыйчыл шигырьләре белән танылган Әбү-Саиди Әбүл-Хайр (ү.е. 440/1049) бүген Төрекмәнистанда урнашкан Мәйханәдә яшәгән һәм шунда ук үлгән. Төрекмән халкы арасында “Мәнә Баба” кушаматы белән искә алынган. Тормыш юлы, хикмәтләре һәм сүзләре Мөхәммәд бине Әбү Рәвһ Лотфулланың (ү. 541/1147) Халату Сүханани, Шәех Әбү Саид вә Мөхәммәд бине Мөнәввәрнең Әсрарут-Тәүһид фи Макаматиә-Шәех Әбү Саид исемле фарсы телле әсәрләре белән бүгенге көндә дә танылган. Мәүлана Җәләлетдин Руминеке булып саналган “Яңадан кил, янә кил, кем булсаң бул, янә кил” дип башланган мәшһүр робагые да чынлыкта Мәүланадан ике гасыр алдан яшәгән Әбү Саиди Әбүл Хайрның шигырьләре арасында урын алган.

“Кәшфүл-*махчүб*” *исемле әсәрен язган Хүҗвири (ү. 465/1072) Фәргана өлкәсендә кайбер суфыйлар белән очрашуы, ул яктагы халыкның шәехләренә “Баб” дип эндәшүен язып калдырган. Чынлыкта бу вакыйга Урта Азиядәге башка өлкәләрдә дә таралган. Әхмәд Ясәвинең янында белем алган Отырарлы Баб белән Арслан Баб төрбәсе эчендә кабеләре урын алган Карга Баб һәм Лачын Баб да бу исемнәрне йөрткәннәр. Нәсәбнамәләрдә Әхмәд Ясәвинең әтисе, бабасы һәм башка кайбер туганнарының “Шәех” дип искә алынулары, бу өлкәдә Ясәвидән алда да суфыйчыл хәрәкәтләрнең әһәмиятле һәм йогынтылы булуын аңлап була. Бу Шәех һәм дәрвишләрнең күчмә һәм җирле төрки халыклар арасында,*

аерым алганда Сырдәрья ярларында һәм далаларда аңлашылучан төрки тел белән халыкка мөрәҗәгать итеп Ислам һәм суфыйчыллыкны таратулары билгеле.

Урта Азия гомумән дини мистика хөкем сөргән Хорасан суфыйчыл мәдәниятенең йогынтысы астында иде. Шуның белән бергә Сәмәрканд һәм Бохара кебек шәһәрләрдә көчле мәдрәсәләре һәм галимнәре булган бу мөхит Хорасанда барлыкка килгән дини агым фикердәшләрен тарату өчен бик тә уңай урын түгел иде. Анда бары тик дини кагыйдәләр белән тыгыз бәйләнештә булган суфыйчылык фәлсәфәсен генә таратып үстерү мөмкин иде һәм нәтиҗәдә шулай булды да. Багдадта Низамийә мәдрәсәсендә белем алып укытучы булган, соңрак Хорасан суфыйчыл мәдәниятендә тәрбияләнеп суфый булган Йосыф Һәмәдани Мәверүннәһердәге бары тик берничә мөридкә генә укытырга рөхсәт ителә. Шул вакытта да Урта Азиянең иң әһәмиятле ике суфыйчыл агымга нигез салына.

Йосыф Һәмәданинең (үе. 535/1140) ике мөһим мөриде Хуҗа Әхмәд Ясәви һәм Габделхалик Гуҗдивани соңыннан Урта Азиянең иң таралган тәрикатьләре Ясәвийә һәм Хаҗиган (алдагы исеме Нәкышҗандиййә) исемле суфыйчыл агымнарга нигез салучы булалар. Йосыф Һәмәдани язып калдырган кайбер суфыйчыл әсәрләр бүгенге көнгә кадәр килеп ирешкән. Боларның иң танылганы “Рутбәтүл-Хайәт” исемле фарсы телле әсәр. Йосыф Һәмәдани дә дини һәм суфыйчыл белем алганнан соң туган җирләре Йәсигә кайтып анда халыкка белем тараткан Хуҗа Әхмәд Ясәви Урта Азиянең фәлсәфи яшәешендә тирән эз калдырган әһәмиятле суфый.



ТОРМЫШЫ

Әхмәт Ясәви Казахстан җирләрендә бүгенге Шимкент каласы янында урнашкан Сайрам исемле кечкенә шәһәрдә дөньяга килгән. Дини тәрбия алганнан соң ул бүгенге Төркистан җирендә урнашкан Ясы шәһәренә килеп урнаша. Тормышының зур өлешен Әхмәт Ясәви шул шәһәрдә үткәрә һәм анда һәрдаим гыйлем туплый һәм халыкка белем тарата, дини тәрбия бирә. Шул шәһәрдә гомере өзелә дә. Аның әтисе Шәех Ибраһим Сайрам шәһәрендә мөридләргә белем биргән һәм танылган суфыйлар рәтендә булган. Кечкенә вакытында ук ятим калган Әхмәт Ясәви Отырар шәһәрендә Арслан Баб исемле Шәех янында кала һәм аннан дини суфыйчыл тәрбия ала. Укытучысының үлеменнән соң башка шәһәрләргә барып укуын дәвам итә.

Шул чорның иң танылган гыйлем үзәге булган Бохарага килеп анда Йосыф Хәмәдани белән таныша һәм аның укучысы да була. Кайбер чыганакларда язылганча Ясәви Шиһабетдин Сүһрәвәрдинең (ү.е 632/1234) яисә Әбү н-Нәҗиб Сүһрәвәрдинең (ү.е. 563/1168) укучысы да булган. Моннан тыш Ясәви башка остазлардан да белем туплаган, аның туганнары арасында Шәехләр дә аз булмаган, әтисе исә Яси шәһәре

хәлифәсе булган Муса Хуҗа белән туганлык җепләре белән бәйләнгән булуы да фараз ителә.

Укуын тәмамлаганнан соң Ясәви Яси шәһәрендә үз җәмгыятен кора һәм кешеләргә дини белем бирә. Үзенең суфыйчыл фикерләрен гади төрки теленә салып шигырьләре аша тарата. Шул рәвешле аның хикмәтләр дип исемләнгән ул шигырьләре вакытлар үткән саен тупланып Диван-и Хикмәт ягъни Хикмәтләр Җыентыгы булып оеша. Кайбер чыганакларда язылганча Ясәви агачтан кашык ясап саткан һәм шул рәвешле көнен күргән. Башка чыганакларда исә аның шактый бай гаилә вәкиле булуы турында да язылган. Аның турында язылган истәлекләрдән аңлашылганча кайбер галимнәр аның җәмгыятендә алып барган зикер ысулларын тәнкыйтьләп чыкканнар. Ясәви үзе исә шигырьләрендә “гадилектән ерак галимнәр һәм ялган суфыйлар”ны тәнкыйтьләгән. Әсәрләрендә иң күп яктыртылган темалары арасында Аллахы тәгаләгә һәм пәйгамбәребезгә мәхәббәт, фәкыйрь һәм ятимнәрне яклау, дини кануннарга хөрмәт, матур әхлак, зикер кылу, нәфескә каршы көрәш, үз-үзеңне тәнкыйть итү, үлем турында уйлау, мәгънәви дәрәҗәләр һәм үз-үзеңне камилләштермичә Шәех дәрәҗәсенә үрмәләүчеләрне тәнкыйтьләү.

Бер риваятьтә язылганча Әхмәт Ясәви 63 яшенә җиткәч дәресханәсендә җир астында аерым бер бүлмә казыткан. Гомеренең калган өлешен күбесенчә шул бүлмәсендә гыйбадәт кылып үткәргән. Соңгы чор чыганакларында Әхмәт Ясәви Хиҗри ел хисабы белән 562 (милади ел хисабы белән 1166-67) елда үлүе турында хәбәр ителсә дә кайбер тикшеренүчеләр аның соңрак үлүе турында әйтәләр.

Әхмәт Ясәвинең Ибраһим исемле улы булган, ләкин әтисе исән чакта ук үлеп киткән. Ясәвинең нәселен аның Гәүһәр исемле кызы

дәвам иттергән. Төркистан, Мәвереннәһер һәм Урта Азиядә, шулар белән берраттән Анатолия җирләрендә дә үзләрен Ясәви нәселеннән дип игълан итүче бик күп шәхес билгеле. Сәмаркандлы Шәех Зәкәрийә, Өскүптан Шагыйрь Ата һәм Әүлийә Чәләби шуларның берничәсе генә.

XIV гасыр ахырында Әмир Тимур Төркистан далаларында даны һәм исеме яңгыраган Әхмәт Ясәвинең каберен зыярәт кылган һәм төрбәсен эшләргә әмер иткән. Берничә ел эчендә төрбәсе, мәчете һәм дәрвишханәсе бөтен бер комплекс хәленә китерелгән. Бүгенге көндә ул төрбә Урта Азиянең иң күп зыярәт ителүче урыннарның берсе булып тора. Әхмәт Ясәвинең кабере һәм төрбәсе арасында йөз метр ара булуы аның дәрвишханәсенең башлыча каберенә якын бер җирдә урнашкан дигән фикер тудыра. Үлеменнән соң күмелгән җирендә вакытлар үтү белән китапханә, ашханә, гыйбадәтханә һәм дәрвиш бүлмәләрен берләштергән зур бер комплекс барлыкка килә.

Әхмәт Ясәви Ясы шәһәрендә белем тарата башлаган вакытта Урта Азиядә актив рәвештә Ислам динен кабул итү, тарату процесслары барган. Ул чорда Ясәви Ташкент һәм Сырдарья артында урнашкан далаларда яшәүче күчмә Төркиләр арасында бик популяр булган. Ислам нигезләрен, матур әхлак, суфыйчылык әдәбен гади аңлашылучан телдә аңлаткан. Моның өчен халык әдәбиятендәге сөйләм техникалары белән үрелгән иҗек рифмасын кулланып шигырьләр иҗат иткән. Аның хикмәт дип исемләнгән шигырьләре дәрвишләре ярдәмендә иң ерак төрки халыкларга кадәр барып ирештерелгән. Шул рәвешле кыска вакыт эчендә Урта Азия төрки халыклары арасында Ясәвилек киң таралыш тапкан.

Мөридләренең берсе Суфи Мөхәммәд Данышмәндинең “Мирагать-әл-Күлүб” исемле әсәрендә Әхмәт Ясәвинең сүзләрен кабатлаган: “Ахыр заманда шундый шәехләр дөньяга таралачак ки, Шайтан алардан дәрес

алыр, алар исә Шайтан кушканны эшләр. Сөннәт әһелләре дошманга әверелер, гөнаһ иәяләре һәм имансызлар дуска әверелер”. Үрнәк өчен хикмәтләренә мөрәҗәгать итик:

Мөршидлекне дәгъва кылыр шартын белмәс

Хәләл – харам, сөннәт, бидагать һич аермас

Хәнифәнең мәсхәбендә һәркем йөрмәс

Башка бидагать мәзхәбенә ия булыр.

Югарыдагы шигъри юллардан Әхмәт Ясәвинең башка Урта Азия төрки халыклары кебек үк сөнни һәм Хәнәфилек динендә булуын күрәбез.

Әхмәт Ясәвинең сүзләрен кабатлаучы иң иске әсәрләрдән берсе Суфый Мөхәммәд Данышмәндинең Мирагать-әл-Күлүб исемле әсәре чагатай телендә язылган. Ясәвинең тормыш юлын яктырткан иң иске әсәр исә Хүсәметдин Сыгнакинеке (үлгән елы 711/1311-1312) дип саналган фарсы телендә язылган әсәр. Бу әсәрләрнең икесе дә бастырылган. Югарыда искә алынган бу ике әсәр Әхмәт Ясәвинең, аның хикмәтләрендәге уй-фикерләренең Урта Азиядә бик танылган булуы һәм аның иң олы шәхесләрдән берсе булын дәлилли.

ӘСӘРЛӘРЕ

1. Хикмәтләр җыентыгы

Ясәвинең төрки телендә язылган шигырьләрен берләштергән җыентык. Хикмәтләр җыентыгының нөсхалары теле ягыннан да, эчтәлеге ягыннан да бер-берсеннән шактый аерылалар. Моны хикмәтләрнең төрле шәхесләр арасыннан күчерелүе һәм туплавы белән аңлатып була. Бер өлеше югалган яисә вакыт үтү белән үзгәртелеп язылган, җыентыклар тупланганда яңа шигырьләр өстәлгән. Шул рәвешле яңа текстлар асыл чыганактан шактый ераклашкан. Ләкин шуңа карамастан бөтен хикмәтләренең нигезендә Ясәвинең ышануы һәм уй-фикерләре белән тарикатенең асылы ята. Хикмәтләр төрки халыклар арасында уртак уй-фикер берлегенең оешу тарихын өйрәнү максатыннан дә бик әһәмиятле. Хикмәтләр җыентыгы һәм иске, һәм дә яңа алфавитта да берничә тапкыр нәшер ителде. Бу басмаларның иң яңасы Әхмәт Ясәви исемендәге Университетның Рәисләр Шурасы җитәкчелеге тарафыннан хикмәтләрнең һәм чагатай телендәге оригиналь тексты һәм дә Хайати Биҗәнең төрекчәгә тәрҗемәсе белән янәшә бастырылды (Анкара, 2016)

2.Факрнамә

Ясәви тарафыннан язылган дип фараз ителгән һәм чагатай телендә язылган “Факрнамә” әсәрен Хикмәтләр җыентыгының Ташкент һәм Казан басмаларында күрәбез. Аерым бер әсәр булудан күбрәк Хикмәтләр җыентыгының кереш өлешен тәшкил иткән “Факрнамә” әсәре Кемаль Эрарслан тарафыннан 1977 елда яңа алфавитка тәрҗемә ителеп Истанбул университеты әдәбият факультетының “Төрек теле һәм әдәбияты” журналының 22нче санында (45-120 битләр) аерым мәкалә булып бастырылган. Әхмәт Ясәви исемендәге университетның Рәисләр Шурасы җитәкчелеге тарафыннан бу мәкалә аерым бер китап булып бастырылды (Анкара, апрель, 2016).

3. Дәр Әдәб-е Тарикат рисаләсе

Фарсы телендә язылган бу кечкенә әсәрнең Ташкентта кулъязма нөсхалары табылган. Әсәрнең төп темалары тәрикатенең кагыйдәләре, мөрид бедән мөршидләр арасындагы мөнәсәбәт, дәрвишлек, Аллаһны тану һәм илаһи мәхәббәт. Бу әсәрне С.Моллаканәгать улы казак теленә тәрҗемә итеп нәшер иткән (Алма-аты, 2012). Нәҗдәт Тосун бу әсәрне фарсы теленнән төрек теленә тәрҗемә итеп Әхмәт Ясәви исемендәге Университетның Рәисләр Шурасы җитәкчелеге аны “Факрнамә” әсәсре белән бергә бастырган (Анкара, ноябрь, 2016)

4. Дәр Макәмәт Әрбагыйн рисаләсе

Ясәви тарафыннан язылган дип фараз ителгән тагын бер әсәр фарсы телендә язылган һәм күләме ягыннан кечкенә. Эчтәлеге шулай ук шәригать, тәрикать, мәгърифәт һәм хакыйкать темаларына багышланган. Һәр темага багышлап 10 макам язылган. Тулаем алганда әсәр 40 макам һәм кагыйдәдән гыйбарәт. Бүгенге көндә сакланып калган бердәнбер нөсхасы Кютахьяда Тавшанлы Зәйтиноглу милли китапханәсендә урын тапкан (№ 1056, 112a-113a). Әсәрне Нәҗдәт Тосун фарсы теленнән төрек теленә тәрҗемә итеп Әхмәт Ясәви исемендәге Университетның Рәисләр Шурасы җитәкчелеге тарафыннан “Факрнамә”, “Дәр Әдәб-е Тарикать” рисаләсе белән бергә нәшер ителгән (Анкара, ноябрь, 2016).

РИВАЯТЬЛӘРЕ

Әхмәт Ясәвинең тормыш юлы турында мәгълумат шактый чикле. Төрки дөньяда Әхмәт Ясәвинең тормыш-яшәеше турында әдәби чыганаклардан түгел дә күбрәк риваятьләрдән беләләр. Бу риваятьләрнең бер өлеше аның тормыш юлы һәм уй-фикерләре турында, икенчеләре исә халык уйлап чыгарган уйдырмалар. Әхмәт Ясәви турында уйлап чыгарылган риваятьләрдән кайберләрен мисал итеп алыйк. Риваятьтә язылганча Арыслан-Баб мәсхәбе җитәкчеләренең берсе булган (Баб - Шәех мәгънәсенә туры килә). Бу сүзне без соңрак язылган әсәрләрдә Баба формасында да очрата алабыз. Мөхәммәд Пәйгамбәребезнең сәяхәтләренең берсендә әһелләре бик ачыккан. Ашарларына бер тәгам ризык та калмаган. Шул мәлдә алар Пәйгамбәребезнең янына килгәннәр һәм аңа ярдәм итүен сорап ялварганнар. Мөхәммәд Пәйгамбәребез догасын ишетеп Җабраил (...) Җәннәттән бер табак хөрмә җимеше китергән. Ләкин җимешләрнең берсе җиргә төшкән.

Моңа каршы Җәбраил шулай дип җавап биргән: “Бу хөрмә җимеше сезнең өммәтегездән Әхмәт Ясәви исемле кешенең өлеше”. Сакларга

ышандырып калган һәр әйберне хуҗасына кайтарырга кирәк. Хөрмә җимешен хуҗасына тапшыру вазыйфасын Мөхәммәд Пәйгамбәребез әсхәбендәге бер вәкиленә йөкләгән. Хөрмә җимешен Арслан Бабның авызына салган һәм озын еллар үтеп туачак Әхмәт Ясәвигә белем-тәрбия бирергә нәсыйхәт иткән. Дүрт йөз ел яшәгән Арслан Баб Сайрам шәһәренә (ягъни Ясигә) килгән һәм йөкләнгән вазыйфасын үтәгән.

Кайбер чыганакларда исә Арсан Баб Әхмәт Ясәвинең әтисе Ибраһим Шәехнең туганы дип тә тасвирлана. Арслан Баб хөрмә төше вакыйгасын төшендә күргән булып соңрак ул риваятьләргә күчкән булырга мөмкин. Хуҗа Әхмәт Ясәви көнен өч өлешкә бүлә торган булган. Көненең зур бер өлешен гыйбадәт һәм зикер кылып үткәргән. Икенче өлешендә исә теләгән кешеләргә белем биргән. Өченче өлешендә исә агачтан кашык, савыт ясаган. Шуларны сатып яшәренә акчан тапкан. Тагын бер риваятендә Ясәвинең үгезе булуы турында хәбәр ителгән. Шул үгезенең сыртына капчык асып, үзе ясаган кашыкларны, савытларны тутырып базарга җибәрә торган булган. Сатып алучылар алган әйберләренең акчасын капчыкның кесәсенә салганнар. Әгәр дә мәгәр берәрсе кашык алып акчасын салмаган булса, үгез ул кеше акчасын салганчыга кадәр аның артыннан калмый йөри торган булган. Кичен исә үгез хуҗасы янына кайта торган булган.

***

Хәрәзмнең Үргәнч шәһәрендә Имам Мәрвәзи (кайсыбер чыганакларда Мергази яисә Мераги буларак та искә алына) исемле бер галим яшәгән. Көннәрдән бер көн аның колагына Әхмәт Ясәви хакында холыксыз сүзләр килеп ирешкән. Имам Мәрвәзи бу сүзләргә ышанган һәм Әхмәт Ясәвине сынап ишеткәннәрен кире кагу максаты белән янына берничә дустын иярткән юлга чыккан.

Юлда барганда ул Әхмәт Ясәвинең төрле җирләрдә күп санлы укучылары барлыгын өйрәнгән. Шулай ук ул меңләгән кеше Ясәви белән күрешеп сөйләшергә хыялланган. Имам Мәрвәзи эченнән: “Мин өч мең төрле сорау әзерләдем, шуларның һәрберсен Әхмәт Ясәвигә бирәм һәм сынап карыйм” дип әзерләнгән. Ул вакыт Ясәви дә тәккәсендә икән. Укучысы Мөхәммәд Данышмәндигә: “Кара әле, кемдер килә ахрсы”, - дигән. Данышмәнди аңа Имам Мәрвәзинең дуслары белән килүен һәм аңа өч мең сорау әзерләгәнен хәбәр иткән. Ясәвинең әмере белән Мөхәммәд Данышмәнди Мәрвәзинең хәтереннән өч мең соаруның бер меңен юк иткән. Соңрак ул икенче укучысы Сөләйман Хаким Атага да тагын бер мең сорауны оныттыруын таләп иткән. Укучысы кушканны үтәгән. Мәрвәзи исендә калган бер мең соравы белән Ясәвинең каршысына килгән: “Аллаһы тәгаләнең колларын туры юлдан яздыручы синме?” дип эндәшкән. Ясәвинең бер дә ачуы чыкмаган. Тик каршы да килмәгән. “Өч көн буена бездә кунак булыгыз, аннары сөйләшербез”, - дигән. Өч көн үткәч алар бер җиргә җыелышканнар. Мәрвәзи сүз әйтергә дип уртага чыккан.Әхмәт Ясәви Хаим Атага боерып калган бер мең соравын да хәтереннән юк иттергән. Хаким Ата Аллаһы тәгаләгә дога иткән. Шуннан соң соңгы сораулар да исендә калмаган Мәрвәзинең. Мәрвәзи авызын ачып ниләрдер сөйләргә теләгән. Ләкин аның хәтеренә бер ни дә килмәгән. Китап һәм дәфтәрләрен ачып аннан укырга теләгән. Ләкин алар да буп-буш чип-чиста икән. Бу хәлгә төшкән Мәрвәзи хатасын аңлаган һәм Ясәвинең укучысына әйләнгән. Аның янында калып зур дәрәҗәләргә ирешкән.

***

Тагын бер риваятьтә Йәси шәһәренә якын бер җирдә Савран исемле авыл турында хәбәр ителә. Анда яшәүче кешеләрнең күбесе мөселман

түгел икән. Алар мөселман Йәси халкына, аеруча Әхмәт Ясәвигә дошманлык хисе белән янганнар. Әхмәт Ясәвинең бөеклеге, хикмәте арткан саен аларның да хөсетлеге арткан булган. Бер көн алар җыелып Ясәвине хур итергә теләгәннәр. Үзләренең бер үгезләрен алып мал суя торган җирдә чалганнар. Итен үзләре белән алып киткәннәр, бары тик тояклары гына калдырганнар. Икенче көн казый янына барып үз хикәяләрен сөйләгәннәр: имеш аларның бер үгезләрен урлап чалганнар, канлы эзләре исә Ясәвинең тәккәсенә китергән аларны. Казый аларга Ясәвинең тәккәсендә барып үгезләрен эзләргә рөхсәт биргәннән соң тәккәгә киткәннәр. Үзләре үк яшереп куйган итне табуга алар Ясәвине хур итәбез дип сөенгәннәр. Тик көтелмәгән бер хәл булып чыккан. Алар эткә әверелеп иткә ташланганнар. Шул рәвешле аларның асыл йөзләре билгеле булган. Бөтен боларны тышта күзәтеп торучылар шаккату катыш курку эчендә Ясәви янына йөгергәннәр. Кылган гөнаһларыннан үкенү хисен белдереп Хуҗадан гафу итүен сорадылар. Хуҗа Әхмәт Ясәви мәрхәмәтле булган, дога кылган. Шуннан соң алар үз кыяфәтләренә кайтканнар. Башка бер риваятьтә исә Савран шәһәре халкы Әхмәт Ясәвинең улы Ибраһимны үтергәннәр, башын кисеп, сөлгегә төреп кавын дип әтисенә китергәннәр.

***

Тагын бер риваятьне күздән кичерик. Хуҗа Әхмәт Ясәви көннәрдән бер көн тәккәсендә утыра икән. Аның янына юлдан үтеп барган бер төркем бала-чага кергән. Алар мәчет янындагы мәдрәсәгә Коръән дәресенә баралар икән. Башка балалар Коръән китапларын букчаларында алып бара, араларында берсе исә, хөрмәт йөзеннән, башы өстенә куеп бара икән. Бу бала дәрестән чыккан вакытта да, остазы утырган җиргә аркасы белән борылмыйм дип, арты белән чигенә торган булган. Боларны күзәтеп

торган Хуҗа Әхмәт Ясәви бер көн балага эндәшкән: “Улым, остазыңнан, әти-әниеңнән рөхсәт ал да, укырга минем яныма кил”, - дигән. Бала да барысыннан да рөхсәт алып Ясәвинең мәктәбенә килгән. Озак еллар янында калып белем туплаган. Үсеп җитлеккәч үзе дә укытучы булган. Бу егетнең исеме Сөләйман икән. Бер көн Әхмәт Ясәви Сөйләйманны берничә дусты белән кырга утын җыярга җибәрә. Шул утыннан учак ягып дәрвишләргә, таләбәләргә һәм килгән кунакларга сый-ризык әзерләргә иде исәбе. Балалар юлга чыккач кына яңгыр ява башлаган. Сөйләйман өске киемен салып утыннары өстенә каплаган. Яшәгән җирләренә кайтканда башка балаларның утыннары юеш икән, бары тик Сөйләман алып кайткан агачлар коры калган. Башкаларның утыннары янмый калган, Сөйләйман алып кайткан утыннар дөрләп янып киткән. Моны күреп аңлаган Ясәви: “Син бик зирәк эш кылгансың. Моннан соң синең исемең дә Зирәк Сөйләйман булсын”, - дигән. Еллар үтеп Әхмәт Ясәвидән укыганлыкка кагәзь (диплом) алган һәм Бакырган шәһәренә күчеп китүе сәбәпле Сөйләйман Бакыргани исемендә танылган.

***

Әхмәт Ясәви яраткан Пәйгамбәр Хәзрәтләренең 63 яшендә үлгәнен исендә тотып, үзе дә шул яшенә җитү белән дөнья гизүеннән туктаган. Вакытының күп өлешен мәдрәсәсендә яисә җир астында казыткан бүлмәсендә гыйбадәт эчендә үткәргән. Иң алдынгы укучыларының берсе Сәед Мансур Ата бу бүлмәгә төшкәч бик тә борчылган. “Шәехем бу тар булмәдә кысан бит”, - дип елый ук башлаган. Шул ук мәлдә аның күзләре ачылган һәм бүлмәнең бер очы көнчыгышка, икенчесе ерак көнбатышка сузылганын күргән һәм никадәр ялгышуын аңлаган.

***

Көннәрдән бер көн Әхмәт Ясәвинең мәдрәсәсенә бик күп укучы җыелган. Урын бик кысан һәм кызу булганлыктан укучылары бик нык тирләгән һәм тир исе тирә-якка таралган. Мәдрәсәнең аскы катында зур бер чаң куйганнар. Агып төшкән бөтен тир шунда җыела һәм тулган саен хуш исле ширбәткә әверелгән. Суфыйлар шул ширбәтне эчкәннәр. Шуннан соң ул чаң “Гашыйк Чаңы” (Хум-и Ашык) исемендә танылган.

ТӨРБӘСЕ

1166 елда Хуҗа Әхмәт Ясәвине үлеменнән соң аның мәдрәсәсеннән 100 метр ераклыкта җирләгәннәр һәм гади генә төрбә ясаганнар. Бу төрбә шул тирәдә яшәгән мөселманнар өчен иң күп зыярәт кылынган урын булган. Ләкин озак вакыт үтми (XIII гасыр башларында) монгол явы бу җирләргә дә килгән һәм аяусыз эзен калдырган. XIV гасырның ахырларында Алтын Урданы үз кулына төшергән Әмир Тимур Монголистан ханы кызын Түкәл Ханымны хатынлыкка сайлап аңа каршы алырга дип юлга чыккан. Юлы Яси шәһәренә туры килгән, анда ул Әхмәт Ясәвиең каберен зыярәт кылган. Шул зыярәте вакытында ул төшендә Әхмәт Ясәвине күргән, Ясәви аңа төшендә бөек җиңү яулаячагын хәбәр иткән. Һәм яхшы хәбәренә сөенче итеп кабере өстендә кечкенә төрбә урынына зурны ясатуын сораган. Яңа төрбәне салу өчен ул заманның иң мәшһүр архитекторы Хуҗа Хөсәен Ширазине җибәргән.

Ике гөмбәзле дүртпочмак формасында эшләнгән бу бинаның үзәк бүлеменең уртасында зур казан урнаштырылган. Җиде төрле металл кушылып эшләнгән бу казан тирәсендә кайбер догалар язылган һәм

казанны ясаучы турында мәгълүмат бирелгән. Элегрәк бу казан эченә баллы су салып Җомга намазына килүчеләргә тәкъдим иткәннәр, һәм бу суның бик тә шифалы булуы турында хәбәр ителгән. Бу казан 1934 елда Сталин әмере белән күргәзмәгә алынган һәм кире кайтарылмаган, Санкт-Петербург шәһәрендә Эрмитаж музеенда калган. Соңрак 1989 елда Казахстан дәүләт эшлеклеләре таләбе белән яңадан төрбәдәге урынына кайтарылган (мәгълүмат өчен: Метин Акар, Тайказан, Әхмәт Ясәви университеты нәшрияты, Анкара, 2017). Өсте гөмбәз формасындагы бу үзәк бүлем тирәсендә ашхәнә, мәчет, китапханә, дәрвиш бүлмәләре, су коесы бүлмәсе (коеханә) кебек төрле-төрле максатлар белән ясалган шактый гына бүлмә бар.

Үзәк бүлемнең очында Урта Азия мәдәниятендә әүлия төрбәләренең символы булган бер Туг (очында ат коерыгы кыллары һәм аләм бәйләнгән озын таяк) урнашкан. Шунда ук ишек тә бар. Ул ишек Әхмәт Ясәвинең кабере урнашкан бүлмәгә – Гүрханәгә алып керә. Агачтан уеп ясалган бизәкле бу ишекнең эчке ягында урнашкан корыч тоткаларның берсендә Хиҗри 797 (Милади 1395) тарихы уелып язылган. Кабер бүлмәсенең өстендә дә кечкенә гөмбәз бар. Ясәвинең кабер ташы ачык яшел төстә. Үзәк бүлемнең тирә-ягындагы бүлмәләрнең кайберләрендә шулай ук каберләр күрергә мөмкин. XVI гасырдан башлап күренекле казах шәхесләре һәм дәүләт башында торган кешеләр монда күмелгән.

Төрбәнең тирә-ягы төсле кермика белән бизәлгән. Керә торган ишекнең тирә-ягы бизәлмәгән. Моның сәбәбен исә Тимурның үлеменнән соң төрбә төзү эшләре дә туктатылган дип аңлаталар. Хәтта үзәк керешнең дә өске өлеше Тимурның үлеменнән соң озак вакыт эшләнмичә калган. Һәм еллар үтеп Хиҗри белән 1000 (1591-1592) елда гына Абдуллаһ Хан әмере һәм ярдәме белән ул өлеше эшләнгән булуы хәбәр ителә. Абдуллаһ Хан заманыннан калган агач терәкләрне бүген дә хәтта күрергә мөмкин.

Төрбәнең тышкы өлешенең өч тарафы Коръән аятьләре белән бизәлгән. Болар Әл-Анам сүрәсенең 59-63 аятьләре. Шулай ук тышкы ягында керамикадан Куфи хат язуы ысулы белән Аллаһ, Мөхәммәд, Әлхамдулиллаһ, Аллаһы Әкбар, Лә илаһе иллаллаһ кебек сүзләр язылган. Төрбәгә керү юлында Улугбәк кызы Әбу-л Хайр ханның хатыны Рәбыйга Султан төрбәсе дә урнашкан.



ЯСӘВИЛЕК

Әхмәт Ясәвинең укучылары аның суфыйчылык фәлсәфәсен һәм уй-фикерләрен вакыт үткән саен Урта Азиянең төрле почмакларына таратканнар. Шул юлдан баручыларны берләштергән агымга дә Ясәвилек исемен биргәннәр. Ясәвилек агымы шулай ук Сильсилә-и Мешәех-и Төрки дип тә йөртелгән. Моның сәбәбен Ясәвилек агымына хас булган Җәһрииййә зикренең күпчелек төркиләр тарафыннан әйтелүе белән дә бәйлиләр. Әхмәт Ясәвинең иң танылган хәлифәләре Мансур Ата, Сәед Ата, Суфый Мөхәммәд Данышмәнди һәм Хаким Ата булган. Ясәвилек агымын күпчелеге белән Хаким ата һәм аның укучылары дәвам иттергән. Асыл исеме Сөләйман Бакыргани булган Хаким ата (үлгән елы 582/1186) суфыйчыл белем алганнан соң Яси шәһәреннән китеп Харәзм якларына юл алган һәм шунда халыкка мәгърифәт тараткан. Остазы Әхмәт Ясәви кебек төрки телдә шигъри рифмага салынган хикмәтләрен сөйләп йөргән Хаким Атаның бүгенге көнгә кадәр Бакырган Китабы дип исемләнгән шигырьләр җыентыгы килеп ирешкән. “Ахыр заман китабы”, “Хәзрәти Мәрьәм китабы” һәм “Мигражнамә” кебек башка шигъри әсәрләр иҗат иткән Хаким Атаның

тормыш юлы һәм яшәеше турында мәгълүмат язучысы билгесез төрки телендә шигъри юллар белән язылган “Хаким Ата китабында” тупланган. Аның “Барысы да яхшы, без яман, бар нәрсә дә бодай, без салам”, шулай ук “Һәр күргәнеңне Хозыр дип бел, Һәр төнеңне Кадер кичәсе дип үткәр” дигән юллары бик мәшһүр. Кабере Үзбәкстанның Каракалпакстан бәйсез өлкәсе Конграт шәһәрендә урнашкан.

Хаким Атаның иң танылган укучысы Зәңги Ата (үлгән елы 656/1258). Ташкентта яшәгән Зәңги Атаның көтүче булуы һәм Хаким Ата үлеменнән соң тол калган Әнбәр Анага өйләнүе турында билгеле. Зәңги Атаның танылган дүрт хәлифәсе - Озын Хәсән Ата, Сәед Ата, Садр Ата һәм Бәдр Ата. Сәед Ата һәм Садр Ата Дәште Кыпчакта урнашкан Сарайчыкка китүе һәм анда яшәүче Алтын Урда хөкемдары Үзбәк Ханны үгетләп Ислам динен кабул иттерүе билгеле. Аеруча Садр Атаның эшчәнлеге нигезендә Үзбәк Ханга ияреп анда яшәүче халык арасыннан 70.000 кешенең Ислам диненә күчүе дә билгеле.

Әхмәт Ясәвинең тагын бер танылган мөриде (хәлифәсе) Суфый Мөхәммәд Данышмәнди үзенә Утырарда мәдрәсә корып белем-мәгърифәт тараткан. Данышмәндинең мәшһүр укучысы Сүзүк Ата (кайбер чыганакларда Сүкчүк Ата дип тә исемләнгән) кушаматлы Шәех Мостафа булган. Шәех Мостафаның хәлифәсе Ибраһим Ата, Ибраһим Атаның улы Исмәгыйль Ата булган. Әтисе үлгәннән соң яңа гына ун яшен тутырып өлгергән Исмәгыйль Ата суфыйчыл белемне Харәзм, Бохара һәм Сәмәрканд шәһәрләрендә дәвам иткән соң Хуҗанд шәһәренә барып Шәех Маслахат Хуҗандидән хилафәт алган һәм туган шәһәре Казыгуртка кайтып белем-мәгърифәт тарата башлаган. Аның улы һәм хәлифәсе Хуҗа Исхак XIV гасырда төрки телдә “Хадикатуль-гарифин” китабын язып калдырган. Китапның эчтәлеге әтисе Исмәгыйл Атаның һәм башка кайбер суфыйларның уй-фикерләренә, Ясәвилекнең

төп кагыйдәләренә багышланган. Исмәгыйл Ата һәм аның улы Хуҗа Исхакның каберләре Турбатта, Казыгуртка якын бер җирдә урнашкан. Югарыда искә алынган Сүзүк ата хәлифәтен Тәрәз шәһәрендә танылган рухани булган "Мәликйөз зүххад" исемле кешегә тапшыруы турында билгеле. Бу шәхеснең онык чыклары Давыд улы Сөләйман һәм Мөхәммәд әл-Кашгарый булган.

Зәнги Атаның укучысы булган Садр-Атадан соң халыкка белем-иршат таратуны Әләмин Баба (кайбер чыганакларда Әймән яисә Алмин дип тә искә алына) белән Гали һәм Мәвдүд Шәехләр дәвам иткән. Мәвдүд тәрикать җитәкчелегеннән аерылганнан соң Ясәвилек агымы ике юнәлешкә аерылган. Юнәлешләрнең берсен Кемал Икани, икенчесен исә Хадим Шәех җитәкләгән. Кемал Шәехтән соң суфыйчыл мәктәпнең эшчәнлеген Галиабади Шәех (Сәет Әхмәт), Шәмсетдин Үзгәнди, Абдал Шәех (Шәех Увайс), Габдулваси Шәех һәм Габделмөхәмин Шәех дәвам иттергәннәр. Бу соңгы затның XVI гасырда Ташкентта яшәгәнлеге билгеле. Араларыннан Шәместдин Үзгәнди "Шәмс-и Аси" исемендә танылган һәм хикмәт формасында шигырьләр язган.

Шәех Хадим җитәкчелегендә эшчәнлеген дәвам иттергән Ясәвия тәрикатенең икенче юнәлеше үз чиратында икегә аерылган. Аларның беренчесен Шәех Хадимнең хәлифәсе Шәех Җәмалетдин Кашгари Бохари җитәкләп алган, аннан соң Сөләйман Газнәви, Сәйед Мансур Балхи (үлгән елы 965/1557), Госманлы Империясе чорында Истанбулга килгән Нәкешбәнди һәм Ясәвийә тәрикатьләре җитәкчесе Әхмәт бине Мәхмүт Хәзиниләр җитәкләгән. Хәзининең әсәрләре арасында: "Җәвахирул-Әбрар мин амваҗил-бихар", "Мәнбаул абхар фи риязил-абрар", "Хуҗәтүл-абрар", "Тасаллаул-күлүб", "Җәмигуль мөршидин" һәм "Диван". Бу тәрикать эчендә Җәмалетдин Кашгари Бохаридән соң яңа бер юнәлеш барлыкка килә. Аны чиратлашып Шәех Худайдад

Бохари Газирәги (үлгән елы 986/1532), Мәүлана Вәли Кух-и Зәри, Шәех Касыйм Газизән Кәрминәги (үлгән елы 986/1578-79). Шәех Пиримнән соң бу юнәлешне Шәех Галим исеме белән дә танылган Мөхәммәд Галим Сыддыки (үлгән елы 1043/1633) җитәкли башлаган. Бу шәхес Милади белән 1033 елда фарсы телендә "Ламахат мин нафахатил-кудс" исемле хезмәтен тәмамлый. Бу хезмәтендә ул Әхмәт Ясәвидән башлап үзе яшәгән көненә кадәр җитәкчелек иткән Ясәвилек агымының Шәехләре турында мәгълүмат язып калдырган. Шәех Галимнең хәлифәсе Мәүлана Госман хәлифәсе Бохаралы Мәүләна Мөхәммәди Имла (үлгән елы 1162/1749-1750) Ясәвилек агымы белән беррәттән Нәкышбәнди агымы әгъзалары арасында да булган. Шәех Галимнең хәлифәләреннән берсе булган Мөхәммәд Шәриф Бохари (үлгән елы 1109/1697) фарсы телендә язылган "Хөҗәтүл-закирин ли раддил-мүнкирин" әсәрендә җәһри зикеренең шаригать тарафыннан тыелмаган булуын исбатлау өчен дәлилләр китергән шулай ук Ясәвилек шәехләре турында мәгълүмат калдырган.Үзе исә һәм Ясәвилек һәм дә Нәкышибәнди тәрикатьләренә кергән. Хикмәт стилендә төрки телендә шигырьләр язган Кол Шәрифнең нәкъ шул зат булуы турында да мәгълүмат та бар. Аннан соң тәрикатьнең башына Фәтхулла Газизән, Лутфуллах Газизән һәм Худайдад бин Таш Мөхәммәд Бохари (үлгән елы 1216/1801) килгән. Күп санлы суфыйчыл эчтәлекле әсәр язучысы Шәех Ходайдадның төрки телендә язылган "Бостанул-мөхиббин" исемле әсәре – Ясәвия тәрикатенең төзелеше һәм җәһри зикере турында әһәмиятле әсәрләр арасында. Аның хәлифәсе Гомәр Ишан Ясәвилек агымы белән беррәттән Нәкышбәндилекнең Мөҗәддидия агымының да әгъзасе булган. XIX гасырның башында Ясәвилек агымы көчен югалткан һәм әкренләп Нәкышбәнди агымы эчендә эреп югала башлаган. Соңгы чорларга караган язма истәлекләрдә без, гомумән, аның турында мәгълүмат очратмыйбыз. XIX гасырның ахырында,

Русия Империясенең Урта Азия җирләрендә хөкем сөргән вакытта, ул гомумән югала.

Без югарыда билгеләп үткән Шәехләрдән кала Ясәвилек агымының башка Шәехләре дә булган, әлбәттә. Ләкин алар турында язма чыганаклар сакланмаган. Мәсәлән, андыйлар арасында Әхмәт Ясәвинең хәлифәләре Баба Мачин, Яшлыг Юныс Ата, Исмәгыйл Ата мөриде Олуг Юныс Ата, Бахаәтдин Нәкышбәнди белән шәхсән таныш булган Шәех Күсәм, Хәлил Ата һәм Пәһлеван Ата, Әмир Күләли улы белән күрешкән Күк Ата, Төркистанлы Тонгуз Шәех, төрки телдә сөйләшүе хакына Төрекчү Ата исеменә лаек булган Ташкент Шәехе һ.б.

Шунысы кызык, кайбер кешеләр Әхмәт Ясәви белән шәхсән күрешмәсәләр дә аны төшләрендә күреп төшләрендә аннан һәм башка Шәехләрдән белем алулары турында бәян иткәннәр. XV гасырда Шәһрисабз шәһәрендә яшәгән Сәййед Әхмәт Бәшири (үлгән елы 868/1463), Хәзрәт Бәшир исеме белән танылган булган, XVI гасырда Көнчыгыш Төркистанда яшәгән һәм Яркәнттә гомере өзелгән Мөхәммәд Шәриф Бузургвар (үлгән елы 963/1556-57) шулардан берничәсе генә булган. Сәййед Әхмәт Бәшири тормышы турында риваять һәм хикәяләр Касыйм Төркистани Насырның фарсы телендә язылган “Хәшт Хадика” яисә “Хадаикуль-җинан” китабында тупланган. Мөхәммәд Шәриф Бузургвар турында хикәятләр исә Мөхәммәт Сиддык Зәлилинең төрки телендә шигъри юллар белән язылган “Тәзкирә-и Мөхәммәд Шәриф Бузугвар” һәм язучысы билгеле булмаган шундый ук исемле һәм шулай ук төрки телдә язылган китапларда урын алган.

Кайбер чыганакларга караганда Ясәвия Шәехләре һәм дәрвишләре арасында татар-болгар җирлегендә яшәүче Әбрәш улы Суфый Бираш, Өфе җирләрендә күмелгән Хөсәен Бәк, Азербайджан шәһәре Ниязабадта җирләнгән Аушар Баба һәм Төркмәнистанда яшәгән Гөзлү Ата кебекләр дә булган.

Фараз ителгәнчә, XV гасыр ахырларында язылган “Вилаятнамә” әсәрендә Кече Азия суфыйларының берсе Хаҗи Бикташи Вәли Әхмәт Ясәвинең хәлифәләреннән булган дип тасвирлануына карамастан Әфлаки тарафыннан XIV гасырда язылган “Менәкибул-арифин” һәм XV гасырда язылган “Ашыкпашазадә Тарих” әсәрләреннән билгеле булганча, Хаҗи Бикташи Вәли Вефаийә тәрикате Шәехе Баба Ильясның (Ильяс Ата исемендә танылган) хәлифәсе булган. Моннан тыш XVII гасырда язылган “Әүлия Чәләби Сәяхәтнамәсе”ндә язылуынча Хаҗи Бикташи Вәли Вефаийә Шәехенең иң яхшы хәлифәләреннән берсе булуы турында язылган. Моны дәлилләү өчен тагын да борынгырак чорда язылган Элван Чәләбинең “Менакибул-кудсийә” һәм “Ашыкпашазадә Тарих” китапларына да мөрәҗәгать ителә. “Вилаятнамә” һәм “Сәяхәтнамә” кебек әсәрләр бик борынгы чорларга караганга, аларның чынбарлыкны сурәтләве шик астына куела. Бу әсәрләрдә Кече Азиядә яшәп Вефаийә тарикате әгъзаләре турында аларның Ясәвия тәракәтенә ия булулары турында язылган. Моның сәбәпләренең берсе Вефаийә тәрикате Шәехе Баба Ильяс Хорасанинең Сәлҗуклы Солтанатына каршы оештырган баш күтәрүләре булырга мөмкин. Халык арасында Исхак Баба баш күтәрүе буларак танылган бу гыйсьян хөкүмәт тарафыннан бастырылган, Вефаийә тарикате әгъзаләре исә качып йөрергә мәҗбүр булган. Аларның бер өлеше исә үзләрен Ясәвийә тәрикате әгъзаләре дип йөртә башлаган. Шул рәвешле бу кешеләр чыганакларда Ясәвийә агымын дәвам иттерүчеләр рәтенә кертелгән. Шул сәбәпле бүгенге көндә Кече Азия һәм Балкан ярымутравында Ясәвийә агымының таралу чикләрен билгеләү мөмкин түгел. Шулай ук XIX гасыр ахырларында Урта Азиянең Фәрганә Үзәне һәм Кыргыз җирләрендә яшәгән Лачы һәм Озын чәчле ишаннарның Ясәвийә тәрикатенә бәйле булып булмавын да билгеләү мөмкин түгел. Бәлки дә нәкъ алар Урта Азиядә бу тарикәть әгъзаләренең соңгыларыдыр.

ЯСӘВИЛЕКТӘ СУФЫЙЧЫЛ ТӘРБИЯ

Багышлау

Багышлау – суфыйчылык юлына аяк басу мәгънәсенә туры килә. Ясәвилектә суфыйчыл белем бирү багышлаудан башлана. Исмәгыйль Ата улы Хуҗа Исхакның XIV гасырында чагатай телендә язылган әсәре “Хадикатуль-арифин” язылганча, Ясәвилектә багышлау тантанасы түбәндәгечә үткәрелгән. Шәех мөридлек нияте белән килгән кешенең кулыннан алган, Аллаһы тәгаләгә мөрәҗәгать итеп тәүбә итүен сораган. Шуннан соң ул өч тапкыр дога кылган: “Әстагъфируллаһ әлләзи ля илаһә илля Һу әл-Һәййел-Каййум вә әсәлүһүт-тәүбә”. Аннан соң кулына кайчы алып Әт-Тахрим сүрәсенең 66 аятен укыган: “Йа әййүһәлләзинә амәнү түбү илаллаһи тәүбәтән нәсүһа”. Шуннан соң гына мөриднең башының башта уң, аннан сул ягыннан, аннары кыл уртасыннан ике-өч бөртек чәчен кисеп алган. Бу рәвешле чәч кисү тәртибе мөриднең дөньяга һәм дөньяви мәшәкатьләргә мәхәббәтен йөрәгеннән кисеп атуны һәм мәгънәви дөньяга йөз тотуын символлаштырган. Шуннан соң Шәех мөриденә нафел намазын кылуын, зикер итүен һәм Шәехенең

рөхсәтеннән башка бер эш тә кылмавын тәкъдим иткән.

Зикер

Ясәвилектә берничә кеше катнашында кычкырып дога укылуга зикер дип әйтелә. Ясәвилектә аерым “зикр-и әррә” дип тә билгеләнгән. Фарсы теленнән “пычкы зикере” дип тәрҗемә ителә. Моның сәбәбе шуның белән бәйле ки, зикер әйтелгәндә дога кылучыларның тавышы пычкы тавышын хәтерләткән. Фараз ителгәнчә XIII гасыр ахыры XIV гасыр башында яшәгән Исмәгыйль Атаның зикер турында язган юллары сакланган: “Тимерче тимерне утта җылытып чүкеч белән тукмаган кебек, мөрид тә йөрәген Һу зикеренең чүкече белән кыйнап чистарта”.

Исмәгыйль Ата мөридләренә зикер әйтүне өйрәткәндә шулай дия иде: “ Әй, Дәрвиш! Тәрикать кардәшләре булдык! Миннән сиңа нәсыйхәт: Бу дөньяны яшел гөмбәз дип күз алдына китер, син дөньяда үзең генә калгансың дип уйла һәм дә Аллаһы тәгалә. Шул кадәр зикер кыл ки Алаһы тәгаләдән башка берни калмасын!” Исамил Ата улы Хуҗа Исхак зикер вакытында Аллаһы тәгаләнең исемнәреннән берсен әйтергә тәкъдим иткән, Хуҗа Әхмәт Ясәви мөридләренә “Аллаһы” яисә “Һу” сүзләренең кулланырга кушкан, Исмәгыйль Ата исә бары тик “Һу” кәлимәсен кулланырга өндәгән.

Чагатай телендә язылган һәм язучысы билгеле булмаган “Рисалә-и Зикр-и Хәзрәт-и Солтан” исемле әсәрдә Ясәвилектә алты төр зикер турында бәян ителә. 1. “Исме зат зикере”. Бу зикерне әйткән вакытта “Аллаһы” сүзе кулланылган, шулай ук “Аллаһы Һу, Аллаһы Һу, Йа Һу, Аллаһы Һу” гыйбарәсе әйтелгән. 2. “Исме сыйфат зикере”. Бу зикерне әйткән вакытта “Һай ah, Һай ah” формуласы кулланылган. Бу зикер төре өйлә намазыннан соң әйтелгән. “Һай” һәм “Ah” сүзләре әйтелгән

вакытта бармаклар йодрыкка бөкләнгән. 3. “Дүсәрә зикере”. Бу зикернең формуласы “Һай ah, Аллаһ, Һай, Һу” һәм “Һай, Һайен, Һу Аллаһ; Һу, Һу, Һу, Аллаһ”. 4. “Һу зикере”. Бу зикернең формуласы: “Һу, Һу, Һу, Аллаһ; Һу, Һу, Һу, Аллаһ”. 5. “Чайкун зикере”. Бу төр зикер әйтелгән вакытта кыңгырау чаңы кулланылган. Зикер формуласы: “Һу (чаң), Һу (чаң). 6. “Чехар дарб зикере”. Зикер формуласы: “Һай, ah ah ah, Һай; Һу, ah ah ah, Һай, Һу. Югарыда искә алынган алты төр зикер төренә өстәмә буларак “Кәбүтәр зикере” (күгәрчен зикере) дә булган. “Һу, Һу” рәвешле әйтелгән.

Һилвәт

Һилвәт – дәрвишләрнең дога кылу яисә дөнья һәм үзе турында тирән уйларга чуму нияте белән ялгызлыкта бикләнүе. Ясәвилектә ялгызлыкта калу – суфыйчыл белем алуның төп элементларның берсе. Ясәвийә агымында һилвәтнең аерым кагыйдәләре дә булган. Хәзининең “Җәвахируль-Әбрар” китабында язылганча, гадәти кагыйдәләрдән аермалы буларак, Ясәвийә тәрикатендә һилвәт төркем белән эшләнгән. Һилвәт кылырга ниятләгән мөридләр мөршидләреннән бер көн алдан рөхсәт алып ураза тота башлаганнар. Һилвәттән бер көн алдан мөридләр иртәнге намаздан соң зикер һәм тәкъбир саннарын арттырганнар. Шул ук көнне икенде намазыннан соң һилвәт кылыначак бүлмәнең ишекләре, мич мөҗалары, барлык тишекләр томаланган. Мөридләр көннең калган өлешен намаз һәм зикер белән дәвам иттергәннәр. Ахшам намазыннан соң ифтарга иң элек кайнар су китерелгән. Мөридләр кайнар су белән авыз ачканнар. Аннан соң кабат су бирелмәгән. Судан соң мөридләргә тары ярмасыннан аш бирелгән. Аштан соң мөридләргә әйрән яисә кечкенә кисәк карбыз тәкъдим ителгән. Ашап бетергәннән соң мөридләр

аять яисә Коръәннән берничә сүрә укыганнар. Сафка тезелеп өч тапкыр тәкъбир әйткәннәр, аннан соң төнгә кадәр дога кылып һәм Аллаһы тәгаләне искә алып вакыт үткәргәннәр. Шул ук вакытта “хикмәт” дип исемләгән илаһиләр укылган. Бөтен болардан соң мөридләрен чәчләрен кырганнар һәм мөридләр һилвәт кылыначак бүлмәнең дүрт почмагына басып тәкъбир әйткәннәр. Шуннан соң зикер кылганнар. Шәмнәр сүнгәннән соң бервакыт ял итеп алганнар һәм ул арада күргән төшләрен Шәехләренә сөйләгәннәр. Һилвәт шул рәвешле кырык көн дәвам иткән. Кырыгынчы көндә ашханәдә эшләүчеләр беренче булып һилвәтне туктатканнар һәм корбан чалганнар. Гореф-гадәт кирәге буенча корбанның каны һәм сөякләре җиргә күмелгән. Чалу сөяге итеннән кәбаб ясалган һәм салкын су яисә әйрән белән һилвәттә катнашучыларга таратылган. Кырыгынчы көннең төнендә суфыйлар яшәгән урыннарына кайтып ял иткәннәр. Икенче көннең иртәнге намазыннан һәм зикердән соң һилвәт тәмамланган дип кабул ителгән.

Сөйләшүләр

Кайбер Ясәвийә Шәехләре суфыйчылык һәм әхлакка багышланган сөйләшүләрнең әһәмиятен ассызыклап шулай дигәннәр: “Намазны күчереп булса да, сөйләшүне күчереп булмый”. Гафил кешеләр һәм хәтта аларның әйберләре суфыйларның күңел тынычлыгын урлаган дип санаганнар. Бер легенданың эчтәлегендә шулай бәян ителә: Хуҗа Әхмәт Ясәви сөйләшү вакытында тиешенчә тынычлану һәм хозурлану хисенә ирешә алмагач мөридләрнең тәккәсендә тентү үткәрергә боера. Алар тынгысыз бер кешенең таягын табып алалар. Бу таякны алып ташлаганнан соң мөридләр һәм остазлары күңел тынычлыгына ирешкән.

Хәлифәт

Суфыйчыл белемен тәмамлаган Дәрвиш халыкка белем-мәгърифәт бирү вәкаләтен алып хәлифә булу хакына ия булган. Ясәвилектә остазлык һәм хәлифлекнең символы буларак укуын тәмамлаган кешегә Шәех тарафыннан таяк бүләк ителгән. Көтүче сарыкларны таяк белән куа-куа көткән, бүреләрдән саклаган кебек, хәлифә дә кешеләрнең мәгънәви тәрбиясе белән мәшгүл булып аларга белем-мәгърифәт биреп нәфес тозакларыннан сакларлар дип өмет ителгән. Суфыйчыл белемнәрен тәмамламаган мөридләргә хәлифәт хакы бирелмәгән. Бу дәрәҗәгә ирешкәннән соң суфыйларда горурлык хисен юк итү максату белән алар иңнәренә кәрзин асып теләнчелек итеп йөргәннәр. Хәлифәт таягы алган кешенең югары әхлак иясе булуы һәм Ясәвилекнең олуг шәхесе Хуҗа Әхмәт Ясәвигә догада булуы өмет ителгән.

Хезмәт

Исмәгыйль Ата улы Хуҗа Исхак тарафыннан язылган “Хадикат-ул Арифин” әсәренең өченче өлеше шәехләр һәм шәехлек вазыйфасына багышланган. Бу бүлектә “шәехлек вазыйфасы – халыкны Аллаһы тәгаләгә чакыру”, “бөтен кешеләргә карата шәфкатьле булу” кебек җөмләләрне күрергә мөмкин. Исмәгыйль Атага: “Халыкны Аллаһы тәгаләгә алып баручы ничә юл бар”, - дип сорау биргәннәр. Аның җавабы шулайрак булган: “Дөньяда никадәр җан иясе булса шул кадәрдер. Ләкин бер мөселман кешегә рәхәтлек кылу һәм файдалы булудан дә якын юл табылмас.”

Нәтиҗә буларак Хуҗа Әхмәт Ясәвине шигырьләре, фикерләре һәм

әсәрләре белән Урта Азиядә исламиятнең, әхлак һәм мәгънәвилекнең таралуына мөһим катнашы булган Аллаһы тәгаләнең дусты дип билгеләргә мөмкин.

Хикмәт формасындагы шигырьләре кыска заман эчендә Анатолиягә кадәр барып җиткән. Юныс Әмрәнең «Бана сәни кирәк, сәни" шигыре һәм Ясәвинең "Миңа син үк кирәк син" (Миңа син генә кирәк син) шигыре бер-берсен эчтәлек ягыннан да форма ягыннан да кабатлап торалар. Госманлы дәүләтендә аеруча Нәкышбәнди агымына караган тәккәләрдә Хикмәтләр җыентыгының кайбер шигырьләре Илаһи көенә укылуы да билгеле.

Госманлы дәүләтенең соңгы елларында Нәкышбәнди-Хәлиди шәехләреннән булган Хаҗи Хасан Шүкрү Әфәнде (үлгән елы 1327/1909) тарафыннан кайбер хикмәтләр чагатай теленнән госманлы теленә тәрҗемә ителгән һәм Тәрҗемә-и Диван-ы Әхмәт Ясәви исемендә бастырылган (Истанбул 1327/1909). Бу күренеш Әхмәт Ясәвинең Урта Азиядән меңләгән километр ераклыкта хәтта гасырлар дәвамында онтылмавының һәм фикерләре дәвам иттерелүнең дәлиле булып тора.

Ясәвинең хикмәтләре гасырлар дәвамында казах далаларында, үзбәк авылларында һәм кыргыз чатырларында яңгырап торган. Үзбәкләр чәйханәләрдә Ясәвинең хикмәтләрен укучыларга "Ясәвихан" исемен биргәннәр. Бу хикмәтләр аеруча Фәргана даласында хатын-кызлар арасында да укылган. Кыргызларның Хикмәтләр җыентыгы һәм Хаким Атаның шигырьләрен берләштергән Бакырган Китабын балаларга укылуы да билгеле. Кыргыз халкына Ясәвилекнең булган тәэсирен шуның белән дә аңлатырга мөмкин ки: кыргызлар ахирәттә Сират күперен кичкәндә аларга Әхмәт Ясәви шәхсән ярдәм итәчәгенә ышанган

булганнар. Хәтта бүгенге көндә Казахстанның Төркистан (иске исеме Яси) шәһәрендә өйләнүче кияү белән кәләшнең Әхмәт Ясәви төрбәсенә барып дога кылулары бу олы күңелле кешенең гасырлар дәвамында хәтере саклануының ачык дәлиле.

БИБЛИОГРАФИЯ

Akar, Metin, Taykazan, Ahmet Yesevi Üniversitesi Yayınları, Ankara 2017

Babadjanov, Bakhtiyar, “Une Nouvelle Sourcesur les Rituels de la Tariqa Yasawiyya: Le Risala-yi Dhikr-i Sultan al-Arifin”, Journal of the History of Sûfîsm, 3 (2001), s. 223-228.

Bice, Hayati, Ahmed Yesevi, İstanbul 2011.

Buhari, Seyyid Zinde Ali, Semerâtü’l-meşâyıh, Taşkent, Özbekistan Fenler Akademisi Biruni Şarkiyat Enstitusu Ktp., nr. 1336, vr. 1a-291b. Buhari, Şeyh Hudaydad b. Taş Muhammed, Bustânü’l-muhibbîn (nşr. B. M. BabacanovM. T. Kadırova), Türkistan 2006, s. 222-224.

Candarbek, Zikiriya, Nasab-nama Nuskaları Cane Turki Tarihı, Almatı 2002.

DeWeese, Devin, Islamization and Native Religion in the Golden Horde. Baba Tükles and

Conversion to Islam in Historical and Epic Tradiion, Pennsylvania 1994, s. 567-573.

Шул ук автор, Devin, The Masha’ikh-i Turk and the Khojagan: Rethinking the Links Between the

Yasavi and Naqshbandi Sufi Traditions, Journal of Islamic Studies, VII/2 (1996), s. 180-207.

Шул ук автор, Devin, The Yasavi Order and Persian Hagiography in Seventeenth-Century Central

Asia, The Heritage of Sûfîsm III: Late Classical Persianate Sûfîsm, Oxford 2000, s. 389-414.

Шул ук автор, “Ясәвийа”, Ислам на территории бывшей Российской Империи, Москва, 2003, том 4, С. 35-38.

Eraslan, Kemal, “Ahmed Yesevi”, TDV İslâm Ansiklopedisi, İstanbul 1989, II, 159-161.

Хаким Ата, *Бакырган Китабы*, Казан, 1884.

Хуҗа Исхак бине Исмәгыйль Ата, Хадикатуль- Арифин”, *Ташкент*, Үзбәкстан Фәннәр Акабемиясе Юируни Шәркыять Институты китап нәшр., № 11838, Б. 1б-131а

Hazini, Ahmed b. Mahmud, Cevâhiru’l-ebrâr min emvâci’l-bihâr, İstanbul Universitesi Ktp., TY, nr. 3893, vr. 15a17b, 25b-26a.

Huseyni, Muhammed Şerif, Huccetü'z-zâkirîn li-reddi'l-münkirîn, Suleymaniye Ktp., Reşid Efendi, nr. 372, vr. 1b-203b.
Kaya, Onal, Tezkire-i Hakîm Ata: Bir Yesevi Dervîşinin Menkabevî Hayatı, Ankara 2007.
Kenjetay, Dosay, Hoca Ahmet Yesevi'nin Düşünce Sistemi, Ankara 2003.
Köprülü, Fuad, Türk Edebiyatında İlk Mutasavvıflar, Ankara 1981.
Mevlana Safiyyu'd-din, Neseb-nâme Tercümesi (hzr. Kemal Eraslan), İstanbul 1996.
Муминов, Аширбек и др. Исламизация и сакральные родословные в Центральной Азии, Алма-Аты, 2008, II, 188-193.
Rafiu'ddin, Seyfuddin Nadirhan Hasan, "Hazini'nin Camiu'l-Murşidin Adlı Eseri Hakkında", Tasavvuf: İlmî ve Akademik Araştırma Dergisi, V/12 (2004), s. 159-166.
Safi, Ali b. Huseyin, Reşehât-ı Aynü'l-hayât (thk. Ali Asgar Mu'iniyan), Tahran 2536/1977, I, 17-34, 97, II, 370-372.
Sıddiki, Muhammed Alim, Lemehât min nefehâti'l-kuds (nşr. M. Nezir Rancha), İslamabad 1986.
Tekcan, Munevver, Hakîm Ata ve Bakırgan Kitabı, Selcuk Un. Sosyal Bilimler Ens. Konya 1997 (yayımlanmamış doktora tezi).
Tosun, Necdet, "Yeseviliğin İlk Dönemine Aid Bir Risale: Mir'atu'l-kulub", *İLAM Araştırma*Dergisi, II/2 (1997), s. 41-85.
Шул ук автор."Ahmed Yesevi'nin Menakıbı", İLAM Araştırma Dergisi, III/1 (1998), s.73-81.
Шул ук автор. "Yeseviyye", TDV İslâm Ansiklopedisi, İstanbul 2013, c. 43, s.487-490.
Yesevi, Ahmed, Dîvân-ı Hikmet (nşr. R. İsmailzade, K. Kari, G. Kambarbekova), Tahran 2000.
Zernuki, Sufi Muhammed Danişmend, Mir'âtü'l-kulûb, İsvec, Uppsala Universitesi Ktp.,nr. 472, vr. 158b-177a.



ХИКМӘТЛӘР

١

عشقنک قيلدي شيدا ميني جمله عالم بيلدي ميني
قايغوم سينسين توني کوني مينکا سينوق کرکسن
اوچماخ کرم جولان قيلام نه حورلارغه نظر قيلام
آني موني مين‌نه قيلام مينکا سينوق کرکسن

٢

قول خواجه احمد زاهد بولمه عاشق بولکيل
بو يول‌لارده بي‌باک يورمه صادق بولکيل
ليلي مجنون فرهاد شيرين وامق بولکيل
عاشق بولماي حق ديدارين کورسه بولماس

٣

اون سيکيز مينک عالمغه سرور بولغان محمّد
اوتوزاوچ مينک اصحاب‌غه رهبر بولغان محمّد
يلانکاچ آچليق‌غه قناعت ليغ محمّد
عاصي جافي امت‌غه شفاعت ليغ محمّد

٤

هر کيم امّت من ديسه رسول ايشين قويمسه
شفاعت کوني بولسه محروم قويمس محمّد
تنکري تعالي سوزين رسول الله سنتين
اينانماکان امتين امت ديمس محمّد

1

Сөюең акылдан яздырды мине, бөтен галәм белде мине
Көнен-төнен кайгым тик син, миңа тик Син кирәк, тик Син
Җәннәте дә кирәк түгел, хур кызларын да теләмим,
Аны-моны ни эшләтим, миңа тик Син кирәк, тик Син

2

Кол Хуҗа Әхмәт! Захит булма, гашыйк бул,
Бу юлларда ялгыз булма, тугры бул.
Ләйлә-Мәҗнүн, Фәрхәт-Ширин, Вамык бул.
Гашыйк булмыйча Хак Тәгаләнгең матурлыгын күреп булмас.

3

Унсигез мең галәмне гиздерүче Мөхәммәд!
Утыз өч мең кешене гиздерүче Мөхәммәд!
Ярлылык һәм ачлыкка канәгать Мөхәммәд!
Күңле саф иманлыга шәфкатьле Мөхәммәд!

4

Һәркем “Өммәтем” дисә, Рәсүл эшен кайгыртмаса
Шул шәфәгать көне булса мәһрүм итмәс Мөхәммәд
Хак тәгалә сүзенә Рәсүлнең сөннәтенә
Инкарьче өммәтенә өммәт димәс Мөхәммәд.

٥

بيزدن درود بسيار يا مصطفي محمّد
تحيات بي شمار يا مصطفي محمّد
امتيدين بولغانلار شفاعتين قولغانلار
اهل بهشت بولغانلار يا مصطفي محمّد

٦

كوركان زمان اينانكان ابابكر صديق دور
اوستون يولوب تيانكان ابابكر صديق دور
ايكنچي سي يار بولغان عدالتليغ عمردور
مؤمنليغده يار بولغان عدالتليغ عمردور

٧

اوچونجي دوستي يار بولغان عثمان با حيادور
هر نفسده يار بولغان عثمان با حيادور
تورتونچي سي يار بولغان شير خدا علي دور
هم معراجده يار بولغان شير خدا علي دور

٨

قيده كورسنک كونكلي سنوق مرهم بولغيل
انداغ مظلوم يولده قالسه همدم بولغيل
روز محشر دركاهي كا محرم بولغيل
ما و منليک خلايقدن قاچتيم منا

5

Бездән Сиңа чиксез сәлам йә Мөхәммәд Мостафа!

Чиксез дога, мәдхия йә Мөхәммәд Мостафа!

Аның өммәтендә булган, шәфәгатен алган,

Алар җәннәт әһелләре булган, йә Мөхәммәд Мостафа!

6

Күреп алгач ышанучы Әбү Бәкер Сиддык.

Өстен булып таянучы Әбү Бәкер Сиддык.

Икенчесе - дусты гадел җанлы Гомәр.

Мөэминлектә дус булучы гадел җанлы Гомәр.

7

Өченче дусты булган яр әдәп иясе Госман.

Һәр сулышында иш булучы әдәп иясе Госман.

Дүртенче дусты булган Хак Тәгалә Арысланы Гали,

Миграждa да дусты булган Хак Тәгалә Арысланы Гали.

8

Күңеле китек кешене күрсәң янына бар мәрхәмәтле бул.

Кем дә мәзлум юлда калса, ялгыз итмә юлдаш бул.

Мәхшәр көне җиткәндә дә Илаһыма якын бул.

“Мин, мин!” – диеп масаючан кешеләрдән качтым мин.

٩

غريب فقير يتيملا رني رسول سوردي
اوشال توني معراج چيقيب ديدار كوردي
قايتيب توشوب غريب فقير حالين سوردي
غريبلا رني ايزين ايزلاب توشتوم منا

١٠

سنت ايرميش كافر بولسه بيرمه آزار
كونكلي قاتيغ دل آزاردين خدا بيزار
الله حقي آنداغ قلغه سجّين طيار
دانالا ردين ايشتيب بو سوز ايديم منا

١١

اي كونكل قيلدينک كناه هركز پشيمان بولمادينک
صوفي مين ديب لاف اوروب طالب جانان بولمادينک
حيف عمرونک اوتي بير لحظه كريان بولمادينک
صوفي نقش بولدونک ولي هركز مسلمان بولمادينک

١٢

بيلماديلا ر ملالا ر انا الحقني معني سين
قال اهلي كا حال علمين حق كورمدي مناسب
روايتلا ر بيتيلدي حالين آني بيلمادي
منصور ديک اولياني قويديلا ر دارغه آسيب

9

Ярлы, фәкыйрь, ятимләрнең Рәсүлебез хәлен сорар иде.
Ул төн Миграҗга чыгып Хак Тәгаләнең матурлыгын күргән иде.
Миграҗтан кайтып килешли фәкыйрьләрнең хәлен сораган иде.
Фәкыйрьләрнең эзеннән бу юлларга төштем мин.

10

Сөннәтебез әйтә: “Кәфер булса да кеше, аны рәнҗетү гөнаһ”
Каты бәгырьле, рәнҗетүче кешеләрне тыяр Аллаһ!
Аллаһ - шаһит күңел рәнҗетүче кешенең тәмугга юлы беренче!
Ишеттем моны галимнәрдән, сөйләүчесе исә мин.

11

Әй күңел гөнаһ кылдың, тик бер дә тәүбә итмәдең,
Мин суфый дидең, Аллаһның эзеннән китмәдең,
Килде – китте гомерең, бер генә дә үкенеп куймадың.
Кыяфәтең суфыйга да охшаса да тик Мөселман булмадың.

12

Белә алмады муллалар “Ана-л Хак” мәгънәсен,
Аллаһы тәгалә моңа рөхсәт бирмәде.
Риваятьләр язылса да, мәгънсенә төшенмәде,
Мансур кебек изге кешеләр үтерелде.

١٣

عالم مين ديب كتاب اوقور معني اوقماس
كوب آيت نينک معنی‌سينی هرگز بيلماس
تكبر من من‌ليک‌نی ديني توتماس
عالم ايرماس جاهل تورور دوستلاريما

١٤

ارادت‌سيز اجازت‌سيز مرشد بولماس
طريقتنينک يول‌لاريني هرگز بيلماس
مبتدع‌دور ارادت‌کا لايق ايرماس
آنداغ‌لاردين يراغ يراغ قاچماق كيراک

١٥

بيشک بيلنک بو دنيا برچه خلقدين اوتارا
اينانمكيل مالينکا بر كون قولدين كيتارا
آتا آنا قريندash قيان كيتي فكر قيل
تورت آياغليغ چوبين آط بر كون سنکا يتارا

١٦

اي دوستلاريم اولسام مين بيلمام كه حاليم نه بولور
كوركه كيريب ياتسام مين بيلمام كه حالم نه بولور
ايلتيب لحدکا قويسه لار ارقه‌غه باقماي يانسه لار
سوروغ سؤاليم سورسه لار بلمام كه حاليم نه بولور

اي قول احمد سين بوكون قيلغيل عبادت تون كون
ديما كيل عمروم دور اوزون بيلمام كه حاليم نه بولور

13

Галим мин диеп китап укый, мәгънәсенә төшенми
Коръән аятьләренең мәгънәсен белми
Тәкәббер кеше Аллаһ юлын таба алмый
Галим түгел, җаһил бит ул, исәтеп куям, дусларым!

14

Ихтыяр көче булмаган, белем алмаган мөршид була алмас
Тәрикать юлларын да үтә алмас.
Бидагать сөйләүчеләрне тыңлаучы булмас
Мондыйлардан ерак тору, качу хәерле.

15

Ышанып белегез, дуслар! Дөнья халыктан күчәр бер көн
Ышанма байлыгыңа, ул кулдан китәр бер көн.
Атаң, анаң, туганнарың кайда бүген шуны уйла,
Дүрт аяклы тактадан ат, сине дә алып китер бер көн.

16

Үлсәм әгәр мин, дусларым! Ни булыр хәлем, белмим?
Кабергә кереп ятсам мин, ни булыр хәлем, белмим?
Кабергә китереп куйсалар, әйләнеп карамый китсәләр,
Миннән сорау алсалар, ни булыр хәлем, белмим?
Әй, Хуҗа Әхмәт, итагатьле бул көн һәм төн,
Гомерем озын дип уйлама, ни булыр хәлем минем?

١٧

هو حلقه سي قورولدي اي درويشلار كيلينكلار
حق سفرهسي يايلدي آندين اولوش آلينكلار
قال علمني اوقوبان حال علمي كا ييتيبان
يوقلوق ايچره ياتيبان بارليقلاردين آلينكلار

١٨

نه خوش تاتليق حق يادي سحر وقتي بولغانده
بالدين سچوك هو آتي سحر وقتي بولغانده
سحر وقتي تورغانلار جانين فدا قيلغانلار
عشق اوتيده كويكانلار سحر وقتي بولغانده

١٩

عاصي جافي قلونک كيلدي دركاهنک كا
قولوم توتوب يولغه سالكيل انت الهادي
ايركليک قادر ييغلاب كيلديم باركاهنک كا
قولوم توتوب يولغه سالكيل انت الهادي

٢٠

كناهم باره باره حدين آشتي
قيامت كون ميني شرمنده قيلمه
باشيم ياستوقده و جانيم كيترده
تنيم باريب لحد ايچره يتارده
صراط اتليق كذاركاهدين اوتارده
قيامت كون ميني شرمنده قيلمه

17

“Һу” зикергә түгәрәкләнеп Дәрвишләр җыеныгыз,
Аллаһының тәм-томнарын килеп авыз итегез.
Гыйлем туплаганнар мәгънәви белемне төшенсен,
Юклыкның тәмен татып Аллаһының юлын таныгыз.

18

Аллаһыга зикер кылу ни хуш таң вакытында.
Балдан татлы “Һу” сүзе таңнар аткан вакытта.
Сәхәргә торучылар җанын фида кылырлар,
Гыйшык утында янарлар таңнар аткан вакытта.

19

Гыйсьянчы колың килде, Йә Раббым бусагаңа.
Кулымнан тот, күрсәт миңа юлымны.
Елый-елый килдем, Йа Раббым, яныңа,
Кулымнан тот, күрсәт миңа юлымны.

20

Гөнаһым күп, чиксез артты, оятсыз.
Кыямәт көнендә мине оят итмә Аллаһым!
Башым ястыкка салып җаным тәслим кылганда
Тәнем кабердә, җаным Сират күперенә юнәлгәндә
Кыямәт көнендә мине оят итмә Аллаһым!

٢١

خوش قدرتليغ پروردكار بير و باريم
قولوم توتوب يولغه سالكيل انت الهادي
ذاتي اولوغ رحمن ايكام هم جباريم
قولوم توتوب يولغه سالكيل انت الهادي

٢٢

انت الهادي انت الحقني ذكري دلده
بيلماس نادان ذكرين ايتيب ظاهر تيلده
مين مين ديكان شيخ زمان آب و گيلده
قولوم توتوب يولغه سالكيل انت الهادي

٢٣

انت الهادي انت الحقني ذكري اولوغ
حق ذكريني ورد ايلاكان كونكلى سنوغ
ورد ايلاماى شيخمين ديسه جايي تموغ
قولوم توتوب يولغه سالكيل انت الهادي

٢٤

راحت تاشلاب جان محنتين خوشلاكانلار
سحرلارده جانين قيناب اشلاكانلار
هاي هوس ما و مينني تاشلاكانلار
چين عاشقدور هركز آني يالغاني يوق

21

Көдрәт көченә ия Аллаһым, барсың һәм берсең!
Кулымнан тот, күрсәт миңа тугры юлымны
Бөек Аллаһым, Рәхмәтлем һәм Рахманым!
Кулымнан тот, күрсәт миңа тугры юлымны

22

“Әнтә-л Хади, Әнтә-л Хади” киртләп куй зикереңдә
Җаһилләр белми, аңламый мәгънәсен зикер кылганда
Замананың Шәехләре җир астында таркала
Кулымнан тот, күрсәт миңа тугры юлымны “Әнтә-л Хади”.

23

“Әнтә-л Хади, Әнтә-л Хади” зикере бөек һәм олы
Аллаһыга зикер кылучының күңеле китек һәм тулы
Зикер кылмаучының - хәтта Шәех булса әгәр – юлы җәһәннәм булыр
Кулымнан тот, күрсәт миңа тугры юлымны “Әнтә-л Хади”.

24

Тән рәхәтеннән баш тартып яшәүчеләр,
Сәхәрләрдә жанын фида итеп тырышучылар,
Һәвәстән, тәкәббәрлектән баш тартучылар -
Һәммәсе чып-чын гашыйк, сүзем һич ялгансыз!

٢٥

عشق دردیني بي دردلا رکا ایتیب بولماس
بو یول‌لا رني عقبه سي کوب اوتوب بولماس
عشق کوهرین هر نامردکا ساتیب بولماس
بي خبرلا ر عشق قدریني بیلکاني یوق

٢٦

عشقه توشتونک اوتقه توشتونک کویوب اولدونک
پروانه‌دیک جاندین کیچیب اخکر بولدونک
دردکا تولدونک غم‌کا تولدونک تیلبه بولدونک
عشق دردیني سورسنک هرکز درماني یوق

٢٧

زاهد بولمه عابد بولمه عاشق بولکیل
محنت تارتیب عشق یولیده صادق بولکیل
نفسني تیفیب درکاهي‌غه لایق بولکیل
عشق سیزلا رني هم جاني یوق ایماني یوق

٢٨

اولوغ کیچیک یارانلاردین ادب کیتي
قیز و ضعیف جوانلاردین حیا کیتي
الحیاء من الایمان دیب رسول ایتي
حیاسیز قوم عجایب‌لا ر بولدي دوستلا ر

25

Гашыйк дәртен дәртсезгә аңлата алмас,

Бу юлның киртәсе юк, үттем дип кенә булмас,

Гыйшык дәртенең асыл ташын сатып мәгънәсе булмас,

Хәбәрсез булганнарның гыйшык кадерен белдем юк!

26

Син гашыйк булдың исә утка төштең яндың,

Утка төшкән күбәләктәй яндың үлдең,

Дәртле гамь белән тулды, саргаеп киптең, сулдың.

“Гашыйк дәрте нидер?” – дисәң, җавабым: дәрманы юк.

27

Заһид һәм гыйбадәтле булсаң, кил син Аллаһка гашыйк бул!

Михнәтләр күр гыйшык юлында, Аллаһка тугры бул!

Нәфсеңне тый һәм Аллаһка лаек бул!

Гашыйк булмаганның җаны юк, иманы юк!

28

Яше-карты ирләрдән әдәп китте,

Кызлардан-хатыннардан итагать китте,

“Әл-һайа-у минәл-иман” - Рәсүл диде,

Итагатьсез халык гарипләнде дуслар.

۲۹

عاقل ایرسنک غریب‌لارني کونکلین آوله
مصطفي‌دیک ایل‌ني کیزیب یتیم کاوله
دنیا پرست ناجنس‌لاردین بویون تاوله
بویون تاولاب دریا بولوب تاشتیم منا

۳۰

غریب فقیر یتیم‌لارني هر کیم سورار
راضي بولور اول بنده‌دین پروردکار
اي بي خبر سن بیر سبب اوزي اسرار
حق مصطفي پندین ایشتیب ایدیم منا

۳۱

محمّد ایدیلار هر کیم یتیم‌دور
بیلینک‌لار اول میني خاص امتیم‌دور
یتیم‌ني کورسنکیز آغریتمنکیزلار
غریب‌ني کورسنکیز داغ ایتمنکیزلار

۳۲

تونلار یاتیب ایومس تلاوت لیغ محمّد
غریب بیرله یتیم‌غه مروّت لیغ محمّد
یولدین آزغان گمراه‌غه هدایت لیغ محمّد
مهم توشسه هر کیمکا کفایت لیغ محمّد

29

Акылың булса, әй нәфсем! Ярлыларның күңелен күр.
Рәсүлүллах кебек гизеп дөнья буйлап ятимнәрне күр.
Тик сак бул, илтифатсыз булма байлыктан мәхрүмнәргә
Аларны уйлап дәрья булдым, елга булып ташыдым мин.

30

Фәкыйрь, гарип, ятимнәрнең һәркем ки хәлен белешер,
Риза булыр ул колыннан, минем рәхимле имандашым,
Һәй хәбәрсез, синнән саклый ул бичараларны
Хак Мостафа үгетен ишетеп сөйләдем мин.

31

Мөхәммәд диде ки: “Ятим булган һәркем,
Белегез, алар минем хас өммәтем,
Ятимне очратсагыз кимсетмәгез,
Ялгыз кешене күрсәгез җанын кыерсытмагыз!

32

Төннәрдә йокламас Корән укып Мөхәммәд,
Бәхетсез һәм ятимнәргә мәрхәмәтле Мөхәммәд!
Юлдан тайган колларга ачулы Мөхәммәд,
Мохтаҗ булган һәркемгә ярдәмче Мөхәммәд!

٣٣

توني كوني اوخلاماي هو ذكريني ايتقانلار
ملائكلار همراهي عرشني اوستيده كوردوم
خير سخا قيلغانلار يتيم كونكلين آلغانلار
چهار يارلار همراهي كوثر لبنده كوردوم

٣٤

اهل دنيا خلقميزده سخاوت يوق
پادشاهلارده وزيرلارده عدالت يوق
درويشلارني دعاسيده اجابت يوق
تورلوك بلا خلق اوستيغه ياغدي دوستلار

٣٥

رسول ايدي صحابهلار بحيل بولونك
آخرتقه اولاندوق سيزانوق بيلينك
روزه توتونك نماز اوقونك زكوة بيرينك
جهنمدين اوزني آزاد قيلماق اوچون

٣٦

بعضي كيشي نماز قدرين قاچان بيلور
هر نمازده ايمان باشدين تازه بولور
صلوة ديسه غافل باشين بوركاب اويور
غافللیق دين عمرين ييل كا ساتار بولغاي

33

Көнен-төнен йокысыз “Һу” зикерен кабатлаучылар
Фәрештәләргә юлдаш алар, Аллаһының янына атлаучылар
Юмарт күңелле, ятимнәрнең күңлен күрүчеләр
Хәлифәләрнең янында атлыйлар, Кәүсәр янында күрдем.

34

Бу дөнья әһелләрендә юмартлык юк,
Падишаһ һәм вәзирләрдә гаделлек юк,
Дәрвишләрнең догасына кабул булу юк,
Төрле бәла халык өстенә яуды дуслар.

35

Рәсүл диде ки: “Әсхабларым тынсыз калыгыз!
Ахирәткә китәм, сез белегез,
Ураза тотып, намаз кылып, зәкат бирегез
Җәһәннәмнән үзегезне азат итегез”.

36

Җаһил кеше намазның кадерен кайдан белсен,
Һәр намазда иманы яңадан ныгысын,
Азан әйтсә дә, гафил кайдан мәгънә аңласын?
Гафиллектән гомерен жилләргә сатып китәр.

٣٧

بو يول‌لارده خارليق زارليق دركار ايرميش
تسبيح تهليل روزه نماز بيكار ايرميش
يالغانچيدين خدا رسول بيزار ايرميش
يالغان نماز ريالارني تاشلاسام مين

٣٨

چين كونكل‌ده نماز قيلغيل خدا بيلسون
خلق ايچنده رسوا بولغيل عالم كولسون
تفراق صفت خارليق تارتقيل نفسنک اولسون
همت بيرسنک نفسيم ييغيب يغلاسام مين

٣٩

روزه توتوب نماز اوقوب توبه قيلغان
سحر توروب الله تيو قولوق قيلغان
مشايخ‌لار خدمتي‌ني تمام قيلغان
آنداغ قول‌لار حق ديدارين كورار ايرميش

٤٠

الكذاب لا امتي ديدي بيلينک محمّد
يالغانچي‌لار قومي‌ني امّت ديمس محمّد
توغري يوركان قوليني حقني ايزلاب يولي‌ني
راست يوركان قوليني امت ديكاي محمّد

37

Хурлыкка калучы һәм елаучы зарар китермәс,
Бары тик намаз, тәсбих, ураза файда бирмәс.
Ялганчыны Рәсүллуллах акламас,
Мин дә ялган намазымны туктатыйм.

38

Йөрәгең белән намазың кыл, Аллаһ белсен,
Халык алдында рисвай бул, галәм көлсен,
Туфрак кебек хур булып күрен, нәфесең басылсын,
Ярдәм ит, нәфесемне җиңеп мин дә елыйм.

39

Ураза тотып намаз кыл, Раббыма тәүбә кыл,
Сәхәрләрдә торып Мәүләгә коллык кыл
Шәехләргә хезмәтенңе кимчелексез кыл,
Бу коллар Аллаһының матурлыгын күрер имеш.

40

“Ялганчылар минем өммәтемнән түгел”, - диде Мөхәммәд,
Ялганчылар кавеменә өммәт димәс Мөхәммәд,
Аллаһының юлын эзләп туры китүчеләргә
Дөрес барган колына тик өммәтем дияр Мөхәммәд.

٤١

غافل‌لارکا دنيا کيراک عاقل‌لارغه عقبي کيراک
واعظ‌لارغه منبر کيراک مينکا سينوق کرکسن
خواجه احمد منم آتم تونې کونې ينار اوتم
ايکي جهانده اميديم مينکا سينوق کرکسن

٤٢

تعالي الله عاشق‌لارکا بيردي عشقين
شاکر بولوب اورتاب يانيب کويدوم منا
ايکي عالم کوزلاريمغه خشخاش دانه
کورونمدي يالغوز حقني سويدوم منا

٤٣

قل هو الله سبحان الله دين قمچي‌سي
روزه نماز تسبيح تهليل حق ايلچي‌سي
پير مغان طالب‌لارني يول باشچي‌سي
قولوم توتوب يولغه سالکيل انت الهادي

٤٤

پير مغان نظر قيلسه بيرکاي دوا
هاي هوس ما و من‌ليک بولغاي ادا
آندين سونکره شيطان لعين سيندين جدا
تار لحده ايمان برلان ياتي بولغاي

41

Гафилләргә дөнья кирәк, акыл ияләренә ахирәт кирәк,
Вәгазь сөйләүчеләргә минбәр кирәк, миңа Сине кирәк Сине
Хуҗа Әхмәт минем исмем, көнен-төнен янар булдым
Ике җиһанда өметем, миңа Сине кирәк Сине.

42

Раббым, гашыйкларга бирде гыйшкын,
Аллаһка рәхмәтемнән янды йөрәгем менә,
Дөньяви теләкләр мәк бертөгедәй миңа
Күренде инде, Аллаһыны сөйдем мин менә.

43

“Көл һувәАллаһ, СөбханАллаһ” - диннең камчысы
Ураза, намаз, тәсбих, тәхлил – Аллаһның газиз илчесе
Шәех Камил талибләргә юл күрсәтүче бикчесе
Кулымнан тот, юлны күрсәт: “Әнтә-л Хади”.

44

Шәех Камил назар тисә кылыр дәва
Хәвәс, нәфес, минминлек чыгар юкка,
Ләгънәт Шәйтан торыр синнән еракта,
Тар кабердә иман белән ятарсың син.

٤٥

اون سيكز مينک عالمده حيران بولغان عاشقلار
تابماي معشوق چراغين سرسان بولغان عاشقلار
هردم باشي اورگولوب كوزي حلقه تيلمروب
هو هو تيو جوركولوب كريان بولغان عاشقلار

٤٦

كويوب يانوب كل بولغان عشقيده بلبل بولغان
كيمني كورسه قول بولغان مردان بولغان عاشقلار
يول اوستيده خاک بولغان سينه‌لاري چاک بولغان
ذكرين ايتيب پاک بولغان نالان بولغان عاشقلار

٤٧

عزت اكرام قرآن‌ني بجا كيلتورمسام
بي ادب‌ليک بي ابالیغ ميندين اوتسه عفو قيل
حضرتينكده من كبي قولني خطاسي كوب ايرور
رو سياه‌ليک هر خطالار ميندين اوتسه عفو قيل

٤٨

بهشت دوزخ تلاشور تلاشمقده بيان بار
دوزخ ايتور من آرتوق منده فرعون هامان بار
بهشت ايتور نه ديرسين سؤزني بيلماي ايتورسين
سينده فرعون بولسه منده يوسف كنعان بار

45

Унсигез мең галәмдә хайран булыр гашыйклар,
Сөекленең нурыннан һушын җуйган гашыйклар.
Һәр мизгелдә бер урында әйләнеп, күзләрен халыкка төбәп,
“Һу, Һу!” дип күз яшьләре аша зикер кылучы гашыйклар.

46

Гыйшыкларыннан көл булган, сөюдән былбыл булган,
Кемне күрсә дә кол булган, мәрдан булган гашыйклар,
Юлларда туфрак булган, бөртек-бөртек таралган,
Зикер әйтеп пакъланган, яшьле күзле гашыйклар.

47

Шул Коръәннең гыйззәтен мин җиренә китермәсәм,
Әдәпсезлек, холыксызлык мин кылсам әгәр гафу кыл.
Хәзрәтеңә каршы хатамны күреп-аңлап бетермәсәм,
Йөз карасы бу хаталарны мин кылсам әгәр гафу кыл.

48

Җәннәт белән Җәһәннәм бер-берсенә дәгъва кылыр,
Җәһәннәм диде: “Мин өстен, миндә Фиргавен, Хаман бар”.
Җәннәт әйтте: “Ни диясең син, ни дисәң дә белми сөйлисең,
Синдә Фиргәвен булса да, миндә Йосыф Кенан бар.”

٤٩

دوزخ ايتور من آرتوق بخيل قوللار منده بار
بخيل لارني بويني‌ده اوتلوغ زنجير كشان بار
بهشت ايتور من آرتوق پيغمبرلار منده بار
پيغمبرلار آلديده كوثر حور و غلمان بار

٥٠

دوزخ ايتور من آرتوق ترسا جهود منده بار
جهود ترسا آلديده تورلوک عذاب سوزان بار
بهشت ايتور من آرتوق مؤمن قوللار منده بار
مؤمن‌لارني آلديده تورلوک نعمت الوان بار

٥١

دوزخ ايتور من آرتوق ظالم قوللار منده بار
ظالم‌لاركا بيرورکا زهر زقوم چندان بار
بهشت ايتور من آرتوق عالم قوللار منده بار
عالم‌لارني كونكلي‌ده آيت حديث قرآن بار

٥٢

دوزخ ايتور من آرتوق منافقلار منده بار
منافق‌لاربويني‌ده اوتدين اشكل كشان بار
بهشت ايتور من آرتوق ذاكر قوللار منده بار
ذاكرلارني كونكلي‌ده ذكر اللهي سبحان بار

49

Җәһәннәм әйтте: “Мин өстен, саран коллар миндәдер,
Сараннарның муенында утлы чылбыр бар.”
Җәннәт әйтте: “Мин өстен, миндә пәйгамбәрләр бар,
Пәйгамбәрләр каршында кәүсәр, хур кызлары, гыйльман бар.”

50

Җәһәннәм диде: “Мин өстен, христиан, яһуди миндә бар,
Христиан, яһуди каршында төрле-төрле газап бар.”
Җәннәт әйтте: “Мин өстен, мөэмин коллар миндә бар,
Мөэминләрнең каршында төрле-төрле нигъмәт бар.”

51

Җәһәннәм диде: “Мин өстен, залим коллар миндә бар,
Залимнәргә бирер өчен агу, газап шактый бар.”
Җәннәт әйтте: “Мин өстен, галим коллар миндә бар,
Галимнәрнең калебендә гыйльме Хәдис, Коръән бар.”

52

Җәһәннәм диде: “Мин өстен, мөнафыйклар миндә бар,
Мөнафыйклар муенында утлы тасмалар бар.”
Җәннәт әйтте: “Мин өстен, закир коллар миндә бар,
Закирларның күңелендә Аллаһ фикере, зикере бар.”

٥٣

دوزخ ايتور من ارتوق بي نمازلار منده بار
بي نمازلار بويني‌ده ييلان بيلان چيان بار
بهشت ايتور من آرتوق ديدار كؤرمک منده بار
ديداريني كورساتورغه رحيم آتليغ رحمن بار

دوزخ انده تيک توردي بهشت عذريني ايدي
قول خواجه احمد نه بيلدي بيلدور كوچي يزدان بار

٥٤

دنيا اوچون غم يمه حقدين اوزكاني ديمه
كشي ماليني ييمه صراط اوزره توتارا
اهل عيال قريندا‌ش هيچكيم بولمايدور يولداش
مردانه بول غريب باش عمرينک يلديک اوتارا

٥٥

كونكل بيرماي دنياغه شروع قيلماي حرام‌غه
حقني سويكان عاشق‌لار خلايقدين كيچميشلار
حرام يكان حاكم‌لار رشوت آليب يكانلار
اوز بارماقين تيشلابان قورقوب توروب قالميشلار

٥٦

عمريم آخر بولغانده نه قيلغايمن خدايا
جان آلغوچي كيلكاندا نه قيلغايمن خدايا
جان بيرمک‌ني وهمدين عزازيل‌ني زخمي‌دين
شفقت بولمسه سندين نه قيلغايمن خدايا

53

Җәһәннәм диде: “Мин өстен, намазсызлар миндә бар,
Намазсызлар муенында елан, чаян бар.”
Җәннәт әйтте:
“Мин өстен, матурлыкны күрү миндә бар.”
Җәһәннәм шунда туктады, гафу үтенде,
Хуҗа Әхмәт бәян итми, белдерүче Аллаһ бар!..

54

Дөнья куып яшәмә син, Хактан башкасын сорама,
Колларның хакына тимә, сиратта күрерсең бер көн.
Бала-чага, иш-дус, туган – һичкем булмас юлдаш,
Акыллы бул дустым, гомерең үтте-китте бүген.

55

Күңлең бирмәсәң дөньяга, кулың сузма хәрәмгә,
Хакны сөюче гашыйклар, әһелләрдән узганнар.
Хәрәмзадә хәкимнәр күпме ришвәт алганнар.
Үз бармакларын хәтта тешләп алып йотканнар.

56

Гомерем ахырына килгәч, мин ни кылыйм Аллаһым?
Җан алучы килгәч тә, мин ни эшлим Аллаһым?
Җан бирүдән куркудан, Газраилнең золымыннан,
Шәфкать булмаса синнән ни итәрмен Аллаһым?

٥٧

جان بيرمک ايشي ديشوار آسان قيلغيل يا جبّار
سندين اوزکا يوق غمخوار نه قيلغايمن خدايا
جانيم جدا بولغانده تنيم مونده قالغانده
تخته اوزره آلغانده نه قيلغايمن خدايا

٥٨

عاجز بولوب ياتقانده فرشته‌لار کيرکانده
من ربک ديب سورکانده نه قيلغايمن خدايا
ايلتيب کورکا قويغانده يتي قدم يانغانده
سورغوچي‌لار کيرکانده نه قيلغايمن خدايا

٥٩

من ربّک ديب تورغانده قرا کوندور اوشنده
ربينک کمدور ديکانده نه قيلغايمن خدايا
قول خواجه احمد سن بنده نفس ايلکيده شرمنده
محشر کوني بولغانده نه قيلغايمن خدايا

٦٠

خوش غايب دين يتوشتي يخشي سوزوم تبرّک
عاشق بولسنک اي طالب رياضت‌ده بيلينک بوک
تون کيچه‌لار اوخلاماي ياش اورني‌غه قانينک توک
ارسلان بابام سوزلارين ايشيتينکيز تبرّک

57

Җан бирү эше бик авыр, син җиңел кыл, Йә Җәббар!
Синнән башкасы юк, җанга тынычлык бирүче Аллаһым!
Җаны тәннән аерылганда, тән туфракка әйләнгәндә
Такталарда сузылып ятып, мин ни кылыйм, Аллаһым?

58

Гажизлек эчендә ятканда, фәрештәләр килгәндә,
“Раббың кем?” дип сораганда мин ни кылыйм, Йә Раббым?
Кабердә калдырып кайтып киткәндә,
Мөнкәрәйн килгәндә мин ни кылыйм, Йә Раббым?

59

“Раббың кем?” дип сораганда, кара көндер ул җирдә,
“Раббың кем?” дип сораганда ниләр кылыйм, Йә Раббым?
Хуҗа Әхмәт бары бер кол, нәфесеңдә гөнаһың бар,
Мәхшәр килгән көннәрдә ниләр кылыйм, Йә Раббым?

60

Хуш гәпьтән өлгерде матур сүзем тәбәрәк,
Гашыйк булсаң әй талиб! Ризаяттә билең бөк.
Төннәрдә һич йоклама, яшең катыш каның түк.
Арслан Бабамның сүзе, тыңлагызчы тәбәрәк.

٦١

ارسلان بابام ايديلار طالب‌لارده يوق اخلاص
پيرينک حاضر بولغانده نه حاجت خضر و الياس
پيرغه قدم قويغانده ياد ايتمه غوث الغياث
ارسلان بابام سوزلارين ايشيتينكيز تبرّک

٦٢

طالب مين ديب ايتورلار والله بالله نا انصاف
نامحرم‌غه باقارلار كوزلاريده يوق انصاف
كيشي مالين ييورلار چون دل‌لاري ايماس صاف
ارسلان بابام سوزلارين ايشيتينكيز تبرّک

٦٣

پير خدمتين قيلدوق ديب طالب مين‌ديب يورارلار
ييپ حرام حريش‌ني كولباريغه اورارلار
كوزلاريده نمي يوق حلقه ايچره كيرارلار
ارسلان بابام سوزلارين ايشيتينكيز تبرّک

٦٤

ذاكر مين ديب زور اورار چيقماس كوزيدين ياشي
دل‌لاريده غمي يوق ناگه آغريغاي باشي
مكر و حيله قيلورلار معلوم خداغه ايشي
ارسلان بابام سوزلارين ايشيتينكيز تبرّک

61

Арслан Бабам боерды, Талипләрдә юк ихлас.
Якты урының әзер булса, кирәк түгел Хызыр Ильяс.
Яктылыкка атлаганда искә төшмәсен кирәксез.
Арслан Бабам сүзләрен тыңлагызчы тәбәрәк.

62

“Талибә мин” дип сөйләрләр булмаса да аларда инсаф.
Хәрәмгә күз төшерәләр, күзләрендә юк инсаф.
Колның хакын алалар булмаса да күңелләре саф.
Арслан Бабамның сүзләрен тыңлагызчы тәбәрәк.

63

“Шәехкә хезмәт иттем” дип үзләрен талиб дияр.
Хәләл-харам дип аермый карынын тутырыр.
Күзләрендә яше дә юк, үзе бик горур йөрер.
Арслан Бабамның сүзләрен тыңлагызчы тәбәрәк.

64

“Закир мин” диеп елар, тик юк күзендә яше.
Күңелләрендә гамь дә юк, авырта һәрчак башы.
Хәйлә корып йөриләр, мәгълум Ходайга аларның эше.
Арслан Бабамның сүзләрен тыңлагызчы тәбәрәк.

٦٥

طالب مين‌ديب ايتورلار كونكليده يوق ذره نور
چين طالب‌ني سورسنكيز ايچي تاشي كوهردور
حقه عيان سرلاري ييميش‌لاري صفا نور
ارسلان بابام سوزلارين ايشيتينكيز تبرّک

٦٦

صورتلاري صوفي نقش قيامت دين قورقماس‌لار
فسق فجور حاصلي كناه‌لاردين هوركماس لار
ريا تسبيح ايلكينده ييغلاب ياشين توكماس‌لار
ارسلان بابام سوزلارين ايشيتينكيز تبرّک

٦٧

ايرانلارني قيلغان‌لارني قيلالمسنک
پيرسيز يوروب ورد اوراد بيلالماسنک
استعانت تيلاب دعا آلالمسنک
خاص بزرک‌لار سيني نه ديب دعا قيلسون

٦٨

دام تزوير قويوب خلقني يولدين اوردونک
شيخ‌ليغ قيليب ريا برله دوكان قوردونک
عشرت قيليب شيطان برله دوران سوردونک
ديداريغه سيني نه‌ديب روا قيلسون

65

“Таләбә мин” дип сөйләрләр, тик юк күңелендә тамчы нур.
Чын таләбәгә карасаң эче-тышы гел хозур.
Аллаһка ачык серләре, ризыклары – сафа-нур.
Арслан Бабамның сүзләрен тыңлагызчы тәбәрәк.

66

Кыяфәте белән суфый, тик кыямәттән куркмыйлар.
Оятсызлыктан оялмыйлар, гөнаһлардан куркмыйлар.
Кулларында тәсбихләре, күз яшен тик түкмиләр.
Арслан Бабамның сүзләрен тыңлагызчы тәбәрәк.

67

Иман кушканча гыйбәдәт кылмасаң,
Иманлы сүзләрне белмичә, Шәехтән качып йөрсәң,
Аннан ярдәм сорап та догасын кылмасаң,
Башка гөнаһ ияләре нигә догасын кылсын?

68

Ямьсез сүзләр сарыф итеп халыкны юлдан чыгардың,
Бастың: “Шәехем!” дидең, дөньяны базар дип уйладың,
Күңелеңнең кәефен күрдең, шәйтанга җаның саттың?
Аллаһ сине матурлыгына ничек лаек әйләсен?

٦٩

توبه قيليب حقه يانغان عاشق‌لارغا
اوچماخ ايچره تورت اريغده شربتي بار
توبه قيلماي حقه يانماكان غافل‌لارغه
تار لحده قاتيغ عذاب حسرتي بار

٧٠

اوچماخ ملكين اومان قول‌لار توبه قيلسون
توبه قيليب حضرتي‌غه ياوق بولسون
حور قصور غلمان ولدان خادم بولسون
الوان الوان كيار تشريف خلعتي بار

٧١

توبه قيلغان عاشق‌لارغه نوري ايرور
توني كوني صايم بولسه كونكلي يارور
قچان اولوب كوركا كيرسه كوري كينكرور
اوغان ايذيم رحيم رحمن رحمتي بار

٧٢

نماز روزه توبه اوزره بارغانلارغه
حق يوليغه كيريب قدم قويغانلارغه
اوشبو توبه برله آنده بارغانلارغه
يارلقانميش قول‌لار برلان صحبتي بار

69

Тәүбә итеп Аллаһ алдында үтәгән гашыйкка
Җәннәт эчендә дүрт чишмәдә ширбәт бар.
Тәүбәсезгә, Аллаһ каршында сүзен тотмаганга
Тар кабердә авыр газап, учак бар.

70

Җәннәткә керергә телүчеләр тәүбә итсен,
Тәүбә белән җаннары чистарсын.
Хур кызлары, вилдан хезмәт итсен,
Төсле күлмәк һәм кадер кафтаны бар.

71

Тәүбә иткән гашыйкларга нур иңәр,
Көнен-төнен ураза тотучыга хозур иңәр,
Үлгән чакта аның кабере яктырыр,
Бөек Аллаһымның ул колына рәхмәте бар.

72

Намаз, ураза, тәүбә кылучылар
Хак юлына кереп юл алучылар,
Тәүбә белән җәннәткә баручылар
Кичерелгән коллар белән гапь корырлар.

٧٣

سندين بورون يارالارينک قيان کيتي
بو دنياغه ميل قيلماي ييغلاب اوتي
عمرينک آخر بولدي نوبت سنکا يتي
کناهنک کا توبه قيلکيل اي بد کردار

٧٤

عشقي تيکسه کويدور کوسي جان و تن‌ني
عشقي تيکسه ويران قيلور ما و من‌ني
عشق بولمسه تانيب بولمس موليم (مولام) سني
هرنه قيلسنک عاشق قيلغيل پروردکار

٧٥

عشق بازاري اولوغ بازار سودا حرام
عاشق لارکا سندين اوزکا غوغا حرام
عشق يوليغه کيرکانلارکا دنيا حرام
هر نه قيلسنک عاشق قيلغيل پروردکار

٧٦

عشق سرّيني بيان قيلسام عاشق‌لارکا
طاقت قيلماي باشين آليب کيتار دوستلار
تاغ و تاشقه باشين اوروب بيخود بولوب
اهل و عيال خانماندين اوتار دوستلار

73

Синең дуслар кайларга китте?

Дөньяларыннан саубуллашмый үтте дә китте.

Гомерем ахырга килде, юл сиңа җитте.

Гөнаһларга тәүбә, әй гөнаһлы кеше!

74

Гашыйк дисәң яндырыр имеш, җанны, җаннарны, тәнне.

Гашыйк дисәң юк итәр һәрнәрсене минминлекне.

Гыйшык булмаса ничек булыр, Аллаһымның коллары, Сине?

Ни булса да Син хәл итәрсең, гашыйк ит безне Аллаһым!

75

Гыйшык базары бөек базар, ул базарда сөю хәрәм.

Гашыйк колга Синнән башка сөю хәрәм, тавыш хәрәм.

Гыйшык юлына басучыларга дөнья хәрәм, дөньявилек хәрәм.

Ни булса да Син хәл итәрсең, гашыйк ит безне Аллаһым!

76

Гыйшыкның серен бәян итсәм, сөйләсәм гашыйкларга,

Түзә алмас,башын алып тауларга китәр, дуслар!

Тауга-ташка башын орып юләрләнеп гизәр,

Бала-чагасын, өен ташлап китәр, дуслар!

۷۷

ديدار اوچون جان‌ني قربان قيلماكونچه
اسماعيل ديک ديدار آرزو قيلمنک دوستلار
جاندين كيچيب طريقت‌كا كيرماكونچه
عاشق من ديب يالغان دعوي قيلمنک دوستلار

۷۸

قول خواجه احمد اوزدين كيچماي دعوي قيلمه
خلق ايچيده عاشق من ديب تيلكا آلمه
عاشق‌ليغي اولوغ ايشدور غافل بولمه
غافل بولوب حق ديدارين كورمنک دوستلار

۷۹

عاشق بولسنک بايزيددیک اوزونک ساتقيل
والله بالله دنيا حرام تاشلاب آتقيل
قانلار توكوب كوزلارينكدين تونلار قاتقيل
بير لحظه‌ده شيطان ملكي ويران بولور

۸۰

بو دنياده فقيرليق‌ني عادت قيلكان
خوارليق تارتيب مشقت‌ني راحت بيلكان
قول خواجه احمد يخشي‌لاركا خذمت قيلكان
قيامت كون انداغ كشي سلطان بولور

77

Аллаһ хакына җаның корбан итмәсәң
Исмәгыйль кебек югары дәрәҗәгә ирешермен димә, дустым.
Җаннан һәм малдан ваз чигеп, тарикатькә кермәсәң,
Ялганчыга гашыйк дәвасы булыр димә, дустым.

78

Син дә Кол Хуҗа Әхмәт, син дә кил ваз кич үзеңнән,
Халык эчендә гыйшкыңны сөйләмә, мактанма.
Гашыйклык бөек эш, могҗизалы эшләрдән,
Ваемсызлык юлы белән Аллаһка ирешелмәс, дустым!

79

Баязит кебек гашыйк бул, кил дә син нәфесеңне сат,
Валлаһи дөнья хәрәм, ал да аны чүпкә ат.
Күзләреңнән канлы яшь түк, төннәр буе шулай ят,
Бер мәл шайтан малы юк булыр, эреп югалыр.

80

Дөньяда фәкыйрьлеккә гадәтләнгән,
Фәкыйрьлек, мәшәкатьне үзенә рәхәт дигән,
Кол Хуҗа Әхмәт син дә игелек иткән,
Кыямәт өнендә алар бәлки дә солтан булыр.

٨١

عاشق بولسنک کیچه کوندوز عشق استاکیل
طاعت قیلکیل کیچه قوپوب هیچ یاتماکیل
عاقل بولسنک نادانلارکا سر ایتماکیل
چین درویشلار طاعت‌لارین پنهان قیلور

٨٢

درویش مین دیب طاعت قیلور خلق ایچنده
ریا قیلیب یوکوروب یورار انده مونده
الله اوچون طاعت قیلکان درویش قنده
چین دوریش‌لار تاغ چول‌نی مکان قیلور

٨٣

قروق زاهد حق عشقی‌نی کوزکا ایلماس
جنت ایزلاب دیدارینی طلب قیلماس
عاشق‌لارنی ناله سیغه قولاق سالماس
بو دنیانی ارقه تاشلاب اتقانی یوق

٨٤

کیلینک ییغلینک ذاکر قول‌لار ذکر ایتالوک
ذاکرلارني خدا بیشک سویار ایرمیش
عشق‌سیزلارني ایماني یوق اي یارانلار
دوزخ ایچره تینماي دایم کویار ایرمیش

81

Гашыйк булсаң көнен-төнен шуны теләрсең,
Сәхәрдә торып хаҗәт намазы кыларсың,
Акылың булса җаһилләргә сер бирмәссең,
Чып-чын дәрвиш гыйбәдәтен качып кылыр.

82

Дәрвиш мин, дип халык эчендә кылыр тәкать,
Риясыз ул һәр көн, һәр мизгел, һәр сәгать,
Кайда ул Аллаһ хакына коллык итагать?
Чып-чын дәрвиш тавы, чүлне яшәү өчен сайлар.

83

Кыланчык суфый гыйшык тотмас,
Җәннәт бәрабәрендә җаның якмас,
Иман чакыруына игътибар итмәс,
Дөньясын аркасына асып этә бирер.

84

Җыелыгыз, һәй дәрвишләр, Аллаһка зикер кылыйк.
Аллаһ искә алучыларны һичшиксез сөярмен дигән.
Гыйшкы юкның иманы булмас, белегезче дәрвишләр,
Җәһәннәм эчендә һәрвакыт янар дигән.

٨٥

قراكوندور اوشال ساعت كه دنيادين سفر قيلسانک
زن فرزند مال ملكنک بار سندين كذر قيلسانک
سني قويماس اجل هرگز نيچه حكمنک روان بولسه
حكومت برله عالمني اكر زير و زبر قيلسانک

٨٦

هو ارّه‌سين آليبان نفس باشيغه ساليبان
توني كوني طالب‌لار جان‌ني قربان قيلينک‌لار
حلقه ايچره هو دينكيز عشق اوتيغه يانينكيز
تن جان برلان طالب‌لار تكبير باشلاب ايتينک‌لار

٨٧

ميني حكمت‌لاريم كيم توتسه محكم
خدا قيلغاي آني البته بي غم
كرار جنت ايچيكا شاد و خندان
خدايم ايلاكاي مسرور و شادان

٨٨

چراغ بولوب اوجماكان دين يوليدين يانماكان
ناحق ايش‌ني ايتماكان عدالت‌ليغ عمردور
مسكين احمد قيلكيل ياد قيلكيل عجزينكني بنياد
شايد روحي شاد قيلكاي عدالت‌ليغ عمردور

85

Кара көн җитәр шул көн, кайчан дөньядан сәфәр китәрсең,
Бала-чага, мал-мөлкәтне ташлап шулай китәрсең.
Сине урап узмас әҗәл, хөкемең, сүзең үтсә дә,
Идарә итеп бар галәмне, астын өскә китерсәң дә.

86

“Һу!” пычкысын кулга алып нәфес башына чалып,
Көнен-төнен зикер кылып җаныңны корбан әйлә син.
Түгәрәк эчендә “Һу!” диегез, гыйшык эчендә яныгыз,
Тәнегез-җаныгыз белән бары тик “Аллаһ” диегез!

87

Минем хикмәтләремне тыңлаучы булса,
Ерак булыр алардан төрле гамь һәм дәрт,
Сөенеп һәм бәхетле керсен җәннәт эченә,
Аллаһым рәхәт өстәсен хозурлык һәм сөенеченә.

88

Чыра булып сүнмәгән, дин юлыннан чикмәгән,
Хаксызлыкны сөймәгән, гадел булган Гомәр.
Мескен Әхмәт йад әйлә, гаҗизлегеңне сөйлә,
Бөек рухны сөендер, гадел булган Гомәр.

٨٩

قهار آتليغ قهرينكدين قورقوب ييغلار خواجه احمد
رحمن آتليغ رحمينكدين اميد توتار خواجه احمد
گناهيم كوب الهيم كيچوركاي سن گناهيم
برجه قول‌لار ايچيده عاصي قول‌دور خواجه احمد

٩٠

بيدار بولغيل اي مؤمن سحر وقتي ايچنده
قوتقار اوزونكني اوتدين سحر وقتي ايچنده
سحرلاردا اول كل‌لار ثنا ايتور بلبل‌لار
كيم ايتور كيم بير و بار سحر وقتي ايچنده

٩١

ايرانلار جمال كورار درويشلار صحبتنده
ايرانلار مجلسينده نور ياغار صحبتنده
نه تيلسه اول بولور درويشلار صحبتنده
هر سرلار ظاهر بولور درويشلار صحبتنده

٩٢

خلايقنينك مزاريغه باريب بر بر تماشا قيل
اولوكلاردين آلوب عبرت كيراك بغرنك كباب قيلسانك
هميشه يخشيليق قيلغيل كيترسن اوشبو دنيادن
قيامت آب رويي‌غه كيراك خون چكر قيلسانك

89

Ул Кәхарнең кәхареннән куркып елар Кол Әхмәт.
Ул Рахманның рәхмәтеннән өметен өзмәс Кол Әхмәт.
Гаебем күп, Аллаһым, Син ярлыка гөнаһым,
Барлык коллар арасында суфый колың Кол Әхмәт.

90

Әй мөэмин, гафил булма, уян сәхәр вакытында.
Җәһәннәмнән коткар үзеңне сәхәр вакытында.
Сәхәрдә ачылыр гөлләр, сайрар былбыллар,
Кем булса да “Аллаһ бардыр һәм бердер”, - дисә сәхәр вакытында.

91

Ышанучылар Аллаһны күрер дәрвишләр сөйләшүендә,
Ышанучылар мәҗлесенең нур ява сөйләшүенә.
Ни теләсә шул булыр дәрвишләр сөйләшүендә,
Барлык серләр ачылыр ышанучылар сөйләшүендә.

92

Кешеләрнең каберенә бар, гыйбрәт ал, назар әйлә,
Үлгәннәрдән гыйбрәт алу кирәк бәгърең телгәнләнсә дә.
Һәр заман игелек кыл, син дә китәрсең дөньядан,
Кыямәтнең нигъмәтенә үзеңне хәзер әйлә.

٩٣

نيت قيلدوق كعبه‌كا رضا بولونک دوستلاريم
يا اولكايميز كيلكايميز رضا بولونک دوستلاريم
نيت قيلدوق كعبه‌كا حق مصطفي روضه‌كا
نصيب قيلغاي بارجه‌كا رضا بولونک دوستلاريم

٩٤

كعبه ساري كوجالوک ظالملاردين قاجالوک
اوغل قيزدين كيچالوک رضا بولونک دوستلاريم
تيليم سورسام قرار يوق غريب اولسه سورار يوق
ييميشلارده حلال يوق رضا بولونک دوستلاريم

٩٥

الله ديكان بنده‌ني جاين جنتده كوردوم
حور غلمان جمله سين قارشو آلديده كوردوم
توني كوني اوخلاماي هو ذكريني ايتقانلار
ملائكلار همراهي عرشني اوستيده كوردوم

٩٦

خير سخا قيلغانلار يتيم كونكلين آلغانلار
چهار يارلار همراهي كوثر لبنده كوردوم
قاضي بولغان عالملار پاره رشوت ييكانلار
انداغ عالم جاييني نار سقرده كوردوم

93

Ният әйләдек Кагъбәгә, хәләлләшик, дусларым!
Йә үлербез, йә калырбыз, хәлләлләшик, дусларым!
Ният әйләдек Кагъбәгә, Хак Мостафа Раузасына,
Насыйп әйләсен һәркемгә, хәләлләшик, дусларым!

94

Әйдә Кагъбәгә күчик, бар залимнәрдән качыйк,
Угыл-кыздан ваз кичик, хәләлләшик, дусларым!
Ялган сүздә карары юк, гарип үлсә сораучы юк,
Җиңелүченең хәләле юк, хәләлләшик, дусларым!

95

“Аллаһ” – диюче колларның урыны җәннәттә, күрдем,
Хур кызлары, гыйльманнарны хезмәтләрендә күрдем.
Көнен-төнен йокысыз “Һу” зикерен кабатлаучыларны
Фәрештәләргә юлдаш Аллаһ янында күрдем.

96

Юмартлык кылып ятим күңелен күрүчене
Җиһарйарлар юлдашы Кәүсәр башында күрдем.
Казый булган галимнәр, акча-ришвәт алучыларны,
Шундый казыйның урынын утлар эчендә күрдем.

٩٧

مفتي بولغان عالملار ناحق فتوي بيركانلار
انداغ مفتي جايي‌ني صراط كوفروكده كوردوم
جماعت‌كا بارمايين ترك نماز قيلغانلار
شيطان برله بر ييرده درك اسفل‌ده كوردوم

٩٨

ظالم بولوب ظلم ايتكان مؤمنلارني آغريتكان
قرا يوزلوك محشرده قولين آرقهده كوردوم
قول خواجه احمد كان آجتي در كوهرني ساجتي
تينكلامكان بو سوزني غفلت ايچنده كوردوم

٩٩

حق قوللاري درويش‌لار حقيقت‌ني بيلميش‌لار
حقه عاشق بولغانلار حق يوليغه كيرميشلار
حق يوليغه كركانلار الله تيو يوركانلار
ايرانلار ايزين ايزلاب مملكتدين كيچميشلار

١٠٠

كونكل بيرماي دنياغه شروع قيلماي حرامغه
حقني سويكان عاشق‌لار خلايقدين كيچميشلار
دنيا منينك ديكانلار جهان مالين آلغانلار
كركس قوش ديك بولوبان اول حرامغه باتميشلار

97

Мөфти булган галимнәр, хаксыз фәтва бирүчеләр,
Шул мөфтиләрнең урынын Сират өстендә күрдем.
Җәмәгатькә бармаучыны, намазларын кылмаучылар,
Шәйтан белән бер җирдә, Җәһәннәмнең түрендә күрдем.

98

Залим булып зөлем кылган, ятим хакына тигән,
Мәхшәрдә кара йөзле, кулын артына бәйле күрдем.
Әхмәт хәзинә ачты, энҗе-мәрҗәннәр чәчте,
Сүземне тыңламаучыны билгесезлек эчендә күрдем.

99

Хак коллары дәрвишләр, хәкыйкатне белгәннәр,
Аллаһка гашыйк булып, Хак юлына кергәннәр.
Хак юлына керүчеләр “Һу!” диеп әйләнгәннәр,
Ышанучы юлын алып мәмләкәттән киткәннәр.

100

Күңел бирмәс дөньяга, кулын сузмас хәрамга,
Аллаһны сөюче гашыйклар, япа-ялгыз калганнар.
Дөнья минеке диючеләр, җиһан малын бетерүчеләр,
Тилгән булып хәрәмләргә батканнар.

١٠١

ملا مفتي بولغانلار ناحق دعوي قيلغانلار
آقني قرا قيلغانلار اول تموغغه كيرميشلار
تاتليغ تاتليغ يكانلار تورلوك تورلوك كيكانلار
آلتون تخت اولتوركانلار تفراق آستين قالميشلار

١٠٢

مؤمن قوللار صادقلار صدقي برله توركانلار
دنيالغين صرف ايتيب اوچماخ حورين قوچميشلار
قول خواجه احمد بيلميش سين حق يوليغه كيرميشسين
حق يوليغه كيركانلار حق ديدارين كورميشلار

١٠٣

عشق سريني بيان قيلسام بو عالمده
بي خبرلار ايشيتيب قولاق توتقاني يوق
حق ياديني كيمكا ايتاي همه غافل
مؤمن من ديب بو دنيادين اوتكاني يوق

١٠٤

ايشان شيخ خواجه ملا دنيا ايزلار
اول سببدين پادشاهلارغه يالغان توزلار
آيت حديث سوزين قويوب مالني كوزلار
حق يوليده هركز محنت تارتقاني يوق

101

Мулла-мөфти булганнар, ялгыш фәтва биргәннәр,
Акка кара дигәннәр, җәһәннәмгә кергәннәр.
Тәмле ризык ашаучылар, матур кием киүчеләр,
Алтын тәхеткә менүчеләр, җир астында калганнар.

102

Мөэмин коллар, тугрылар, Аллаһ өчен янганнар,
Дөньялыкны сарыф итеп, хур кызларын алганнар.
Хуҗа Әхмәт белгәнсең, Хак юлына кергәнсең,
Аллаһ юлына басучылар, Матурлыгын күргәннәр.

103

Гыйшыкның серен бәян итсәм бу галәмдә,
Хәбәрсезләр ишетеп игътибар бирәсе юк.
Аллаһ исемен кемгә сөйләсәм, гафилләр бу галәмдә,
Минминлек кылып дөньядан ваз кичәсе юк.

104

Суфый, Шәех, мулла барысы дөньяны күзләр,
Шуңа күрә солтаннарга һәрвакыт ялган сөйләр.
Аять, хәдис онытып киләчәк малны күзләр,
Аллаһ юлында михнәтне мәңге чигәсе юк.

١٠٥

جنازنكني اولوغ كيچيک كوتارسهلار
كورستانغه قراب سيني يوروتسهلار
ييتميش ييرده سؤال سورسه فرشتهلار
بر بر آني جوابيني بيرماق كيراک

١٠٦

عمرينک آخر بولغوسي‌دور بر كون تمام
بو ايش برلان بارسنک اكر دار السلام
حلال قويب يكان بولسنک دايم حرام
عذابي‌ني باريب آنده تارتماق كيراک

١٠٧

ايا دوستلار آخر زمان بولدي كورونک
بي دين كافر بو عالمغه تولدي كورونک
حق قوللوغين قويوب بارجه فاسق بولدي
انينک اوچون قهار غضب قيلدي كورونک

١٠٨

صوفيا بي غم يورارسين دانة تسبيح آليب
دنياغه مغرور بولوب دين ايشيني آرقه ساليب
قورققيل ايمدي قورققيل ايمدي خداغه يلباريب
صوفي نقش بولدينک ولي هركز مسلمان بولمادينک

105

Олы-кечкенә димәдән, җеназаңны күтәрсәләр,
Синең белән бергә атлап каберстанга барсалар.
Җитмеш җирдә фәрештәләр сиңа сорау бирсәләр.
Берәм-берәм сорауларга җавап бирүең кирәк.

106

Ахырда бер көн булыр, бу фани гомерең тәмам,
Иман белән күчсә кабергә, бу йортка бирерләр сәлам,
Хәләлне ташлап исә дөньяда кылсаң хәрам,
Анда калып газабын чигү булыр насыйп.

107

Һәй минем газиз дусларым! Ахыр заман килде, күрегез.
Динсез, кяфер, күпме гөнаһлы бу дөньяга тулды, күрегез.
Аллаһның колы булып кыланганнар күрегез.
Аның өчен кәхар булып, газап чикте менә күрегез.

108

Гәмьсез йөзең, һәй вәли! Тәсбих бөртекләрен алып,
Дөньда горур булырсың, дин эшен кулыңа алып.
Курык инде, курык һәй гафил, Аллаһыга ялварып,
Суфый холыклы булдың әмма мөселман булмадың.

١٠٩

احمدا سين صوفي بولسنک صوفيليغ آسان ايماس
حق رسول صوفي بولوب دنيا مالين سويکان ايماس
دنياني سويکان کيشي بي شک بيلينک انسان ايماس
صوفي نقش بولدونک ولي هرکز مسلمان بولمادينک

١١٠

قاضي مفتي ملالار شريعت درکاهني
عارف عاشق آليب‌دور طريقت‌ني ارکي‌ني
عمل قيلغان عالم‌لار دينميزني چراغي
براق مينار محشرده ايگري قويار بورکي‌ني

١١١

رهنمادور خواجه احمد کلستان معرفت
سوزلار سوزي حقيقت آجار کونکل ملکي‌ني
مسکين ضعيف خواجه احمد يتي پشتينک کا رحمت
فارسي تيل‌ني بيليبان خوب ايتادور ترکيني

١١٢

طريقت کا شريعت‌سيز کيرکانلارني
شيطان کيليب ايماني‌ني آلور ايرميش
اوشبو يول‌ني پيرسيز دعوي قيلکانلارني
سرسان بولوب ارا يولده قالور ايرميش

109

Әй, Әхмәт! Син суфый булсаң, бел суфый булу җиңел түгел,
Аллаһының Рәсүле суфый булып, дөнья малын сөйгәннәрдән түгел,
Дөнья малын сөйгән кеше һич шөбхәсез кеше түгел,
Суфый кебек булдың, һәй вәли! Тик мөселман булмадың!

110

Казый, мөфти, муллалар юлында шәригатнең,
Мәгариф, гыйшык алган, шәфкатен тәрикатнең,
Гыйльме белән галим булган, чырасы хакыйкатнең,
Бурак менәр мәхшәрдә, төз тотар гәүдәсен.

111

Мөршид булган Хуҗа Әхмәт, биргән йөрәкләргә сафа,
Сүзләре чынбарлыкны ачкан , күңелләрнең илен,
Әй, мескен Хуҗа Әхмәт! Җиде буыныңа рәхмәт!
Фарсыча да белгән, матур сөйләгән төркичәне!

112

Тәрикатькә шәригатьсез кергәннәрнең,
Шәйтан килеп иманнарын алыр имеш.
Бу зур юлга Шәех булмастан чыкканнарны
Хәйран кылып ярты юлда адаштырыр имеш.

١١٣

طريقت كا سياست‌ليغ مرشد كيراك
اول مرشدكا اعتقادليغ مريد كيراك
خذمت قيليب پير رضاسين تاپماق كيراك
موندا غ عاشق حق‌دين اولوش آلا ر ايرميش

١١٤

خوشلامايدور عالم‌لا ر سزني ايغان تورکيني
عارف‌لا ردين ايشتسنک آچار کونکل ملکي‌ني
آيت حديث معني‌سي تورکي بولسه موافق
معني‌سي کا يتکانلا ر يير کا قويار بورکي‌ني

١١٥

اوشبو يولغه اي برادر پيرسيز کيرمه
حق ياديدين لحظه غافل بولوب يورمه
ماسواکا عاقل ايرسنک کونکل بيرمه
شيطان لعين اوز يوليغه سالور ايرميش

١١٦

ايا دوستلا ر هيچ بيلماديم مين يولوم‌ني
سعادت‌غه باغلامديم مين بيليم‌ني
ماسوادين هيچ ييغماديم مين تيليم‌ني
نادان‌ليقيم مينې رسوا قيلور ايرميش

113

Тәрикатькә сәясәтле мөршид кирәк,

Ул мөршидкә итагатьле мөрид кирәк,

Хезмәт кылып Шәех ризалыгын алу кирәк.

Шундый гыйшык Аллаһтан ризалык күрер имеш.

114

Төрки телне хуш итмәгән галимнәр,

Ачарлар күңел ишеген тыңласалар мәгърифәтлеләр,

Аять, хәдисләрнең мәгънәсе төрки телдә бик матур диделәр,

“Җиргә куяр бүреген” җөмләсенең мәгънәсен белүчеләр.

115

Һәй, кардәшем! Син бу юлга Шәехсез кермә,

Аллаһ юлында гафил булып йөрмә,

Акыллы булсаң динсезлеккә күңел бирмә.

Ләгънәтле шәйтан юлына гафилләр керер имеш.

116

Һәй дусларым! Белә алмадым юлымны,
Сәгадәткә бәйләмәдем билемне,

Юк-бар сөйләүдән һич тыймадым телемне,

Җаһиллегем мине пошаман итәр имеш.

۱۱۷

شريعتني طريقتني بيلاي ديسنک
طريقتني حقيقتکا اولاي ديسنک
بو دريادين درّ و گوهر آلاي ديسنک
جاندين کيچان خاصلاري آلور ايرميش

۱۱۸

عاشق قول‌لار کيچه کوندوز هرکز تينماس
بر ساعتي حق ياديدين غافل بولماس
انداغ قولني سبحان ايکام ضايع قويماس
دعا قيلسه اجابت‌ليغ بولور ايرميش

۱۱۹

وآه دريغا کيچتي عمروم غفلت بيلان
سين کيچورکيل کناهلاريم رحمت بيلان
قول خواجه احمد سنکا ياندي حسرت بيلان
اوز اوزيغه اوزي يانيب کويار ايرميش

۱۲۰

يسوي حکمتين دانا ايشتسون
ايشيتکانلار همه مقصودغه يتسون
جواهر کانيدين بير نکته آلسون
ايشيتماکان باري حسرتده قالسون

117

Шәригатьне, тәрикатьне белим дисәң,
Тәрикатьне хакыйкатькә бәйлим дисәң,
Бу дөньядан энҗе-җәүһәр алыйм дисәң,
Җанга якын кешеләрне алыр имеш.

118

Гашыйк коллар, көнен-төнен тынгы белмәс,
Аллаһ юлында бер сәгать тә ял итмәс,
Бөек Мәүлә колын авыр чакта ташламас,
Дога итсә, колына ярдәм итәр имеш.

119

Вах! Ни кызганыч, үтте гомрем гафиллектә,
Син ярлыка гөнаһларымны рәхмәтең белән,
Хуҗа Әхмәт син дип янды хәсрәт эчендә.
Үз-үзен яндырып хәлак булыр имеш.

120

Ясәви Хикмәтләрен бар галимнәр ишетсен,
Ишеткәнәр үз максатына ирешсен.
Җәүһәр хәзинәсеннән бер микътарны кереп алсын,
Ишетеп күрмәгәннәр һәрдаим хәсрәттә калсын.

۱۲۱

ميني حكمت‌لاريم قند و عسل‌دور
همه سوزلار ايچنده بي بدل‌دور
ميني حكمت‌لاريم انعام الله
سحر وقتده ديسه استغفر الله

۱۲۲

ميني حكمت‌لاريم دردسيزكا ايتمنک
بهاسيز گوهريم نادانغه ساتمنک
يسوي حكمتين قدريغه ياتقيل
خم عشقدين مي بر قطره تاتقيل

۱۲۳

پير رضاسي حق رضاسي بولور دوستلار
حق تعالي رحمتيندين آلور دوستلار
رياضت‌ده سر سوزيدين بيلور دوستلار
آنداغ قول‌لار حقّه ياوق بولور ايرميش

121

Хикмәтләрнең ахыры шикәр, бал һәм шифа,

Барлык сүзләр эчендә дәрткә чара һәм дәва.

Аллаһының нигъмәтедер, бу минем Хикмәтләрем,

Сәхәр вакытларында Әстәгъфируллаһ диярмен.

122

Минем Хикмәтләремне дәртсезләргә сөйләмә,

Кыйммәтен белмәс җаһилгә җәүһәрләрне таратма.

Ясәви Хикмәтенең мәгънәләрен аңлат

Гыйшык савытыннан бер тамчы, бу мәйдән кил син дә кап.

123

Шәех ризасы, Аллаһ ризасы булыр, дуслар,

Хак Тәгалә рәхмәтенә алыр, дуслар,

Риясызлыкта сер сүзен таный дуслар,

Андый коллар Аллаһка якын булыр икән.

СЫЛТАМАЛАР:

1. Хикмәт: Hoca Ahmed Ясәви, Dîvan-ı Хикмәт (нәшерләре: Кунышбәк Кари, Галия Камбарбекова, Расуль Исмаилзадә), Тәһран: el-Hüdâ, 2000, s. 186-1878.
2. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 1268.
3. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 558.
4. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 548.
5. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 56, 578.
6. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 1008.
7. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 101-1028.
8. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 178.
9. Хикмәт: Ясәви, шунда ук,б. 17.
10. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 208.
11. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 1658.
12. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 528.
13. Хикмәт: Hoca Ahmed Ясәви, Dîvân-ı Хикмәт (хәзерләүче Дайрабай Серикбайулы, С.Рафиддинов), Алма-Ата: ARIS, 2001,б. 428.
14. Хикмәт: Ясәви, Dîvân-ı Хикмәт, Тәһран, 2000, б. 156; Ясәви, шунда ук, Almatı 2001,s. 164-165.
15. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, Tahran 2000, б. 35.
16. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, Алма-Ата, 2001,б. 105-106.
17. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, Алма-Ата, 2000,б. 95.
18. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, Алма-Ата, 2001,б. 226.
19. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, Тәһран, 2000,б. 220.
20. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, Тәһран, 2000,б. 201-202.
21. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 222.
22. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 223.
23. Хикмәт: Ясәви, , б. 223.
24. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 148.
25. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 148.

26. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 149.
27. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 149.
28. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 68.
29. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 18.
30. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 19.
31. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 99.
32. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 55.
33. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 175.
34. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 69.
35. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 196.
36. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 209.
37. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 180.
38. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 180.
39. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 138.
40. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 54.
41. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 187.
42. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 38.
43. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 222.
44. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 208.
45. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 92.
46. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 93.
47. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 173-174.
48. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 61.
49. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 61.
50. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 62.
51. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 62.
52. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 62.
53. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 61-62.
54. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 35.
55. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 94.
56. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 50.
57. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 50.
58. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 50.
59. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 50.
60. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 151.
61. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 151.
62. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 151.
63. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 151.
64. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 151.
65. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 151.

66. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 151-152.
67. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 194.
68. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 194.
69. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 60.
70. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 60.
71. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 60.
72. Хикмәт Ясәви, шунда ук, б. 60.
73. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 63.
74. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 64.
75. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 65.
76. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 72.
77. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 77.
78. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 79.
79. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 107.
80. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 107.
81. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 111.
82. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 111.
83. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 147.
84. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 135.
85. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 160.
86. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 95.
87. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 235.
88. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 101.
89. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 59.
90. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 201.
91. Хикмәт: Ясәви, Dîvân-ı Хикмәт, Алма-Ата 2001, б. 227.
92. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, Тәһран, 2000,б. 160.
93. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, Тәһран, 2000,б. 175.
94. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 176.
95. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 174-175.
96. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 175.
97. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 175.
98. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 174-175.
99. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 94.
100. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 94.
101. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 94.
102. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 94.
103. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 145.
104. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 145.
105. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 159.

106. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 159.
107. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 160.
108. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 166.
109. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 167.
110. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 225.
111. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 226.
112. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 132.
113. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 132.
114. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 132.
115. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 132.
116. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 132.
117. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 132.
118. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 133.
119. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 133.
120. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 234.
121. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 235.
122. Хикмәт: Ясәви, шунда ук, б. 235.
123. Хикмәт. Ясәви, шунда ук, б. 225.

